http://algaburaevo.ru

# Алга

№1 (11544)
Чәршәмбе
5 гыйнвар
2022 ел.

12+

Башкортстан Республикасы Борай районы муниципаль районының иҗтимагый-сәяси газете

Газит 1930 елның 19 февраленнән чыга.

Бәясе ирекле

## Раштуа белән!



***Районыбызның хөрмәтле православие христианнары!***

*Сезнең барыгызны да 7 гыйнвар – изге бәйрәм – Христос Раштуасы белән чын йөрәктән котлыйбыз!*

*Христос Раштуасы гаилә, аналар һәм балаларның бөек кыйммәтләрен зурлый һәм раслый, кешеләрнең күңелләрендә өмет, мәхәббәт һәм иманны ныгыта, аларга тормыштагы авырлыкларны җиңеп чыгарга көч бирә.*

*Районыбызда төрле дин тотучылар арасында үзара ихтирамлы мөнәсәбәтләр яшәп килүе куанычлы хәл. Бу күренешләр халыкларыбыз арасында дуслыкны, килешеп яшәүне ныгытуга булышлык итә.*

*Раштуа бәйрәме йортыгызга иркен тормыш һәм муллык алып килсен, йөрәкләрдә тынычлык, мәхәббәт һәм шатлык, изге ихтыяр һәм рух сафлыгы тантана итсен!*

*Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, бетмәстөкәнмәс рухи көч, барлык изге эшләрегездә һәм башлангычларыгызда уңышлар телибез!*

**Муниципаль район Советы.**
**Муниципаль район хакимияте.**

# Ачык һәм кыю интервью

**28 декабрьдә Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров зур интервью форматында БСТ телекомпанияләре, “Башкортостан” дәүләт телерадиокомпаниясе һәм “Башинформ” мәгълүмат агентлыгы җитәкчеләре сорауларына җавап бирде. Радий Хәбиров республика үсешенең төп нәтиҗәләрен 2021 елда ясады, казанышлар, кыенлыклар һәм киләчәккә планнар турында сөйләде.**

Туры эфирда Башкортстан Башлыгына коронавирус белән бәйле хәл турында да сораулар бирелде. Алар арасында – тагын чикләүләр булырмы, ковид белән көрәшүче табибларга нинди дәртләндерү чаралары күрелә, “омикрон”нан безгә ниләр көтәргә, “антиваксер”ларга мөнәсәбәте һәм башкалар.

Радий Хәбиров, кабул ителгән чикләү чараларыннан тыш, башка чикләүләр кирәкмәс, дип билгеләде. Яңа елдан соң хәлнең ничек булачагын күзәтергә һәм хәлгә карап карарлар кабул итәргә кирәк икәнен әйтте.

Республика җитәкчесе табибларга өстәмә түләүләрнең дәвам итәчәген ассызыклады. “Медицина хезмәткәрләренә иң башта яхшы эш шартлары тудыру, яхшы дәваханәләр, поликлиникалар булдыру мөһим”, – дип билгеләде республика Башлыгы.

“Омикрон” штаммының бөтен дөньядагы киңкүләм проблема булуын, кайбер илләрнең инде өчәр атна локдаунда булуын әйтте Радий Хәбиров. “Ул безгә һичшиксез киләчәк. Безне шул гына тынычландыра – без 2 миллион 178 мең кешене вакциналадык. Коллектив иммунитетка ирешү өчен бу сан 2 миллион 450 мең булырга тиеш. Ревакциналанучылар да арта.

Төбәк җитәкчесе билгеләвенчә, 2021 ел 2020 елдан авыррак булган. “Без 2020 елны иң авыр ел булды дип билгеләгән идек. Ләкин 2021 елдагы югалтуларны күргәч, без аның әле “ак ел” булуын аңладык”, – диде ул.

Антиваксерлар турындагы сорауга җавап итеп, республика Башлыгы бу кешеләрне “вакциналану темасында “хайповать” итәргә, шуның белән үзләрен рекламаларга теләүчеләр” дип билгеләде. Бу кешеләргә карата тыныч һәм ышанычлы итеп аңлату эшләре алып барырга кирәклеген әйтте. Ковид-госпитальдә күргәннәреннән чыгып, вакциналанмаган кешеләрнең ни дәрәҗәдә авыр чирләве хакында мисал да китерде республика Башлыгы.

2021 елда республикада күп кенә киңкүләм, халыкара чаралар узды. Пандемия булу сәбәпле, бу уңайдан халыктан тәнкыйть сүзләре дә ишетергә туры килде. Туры эфирда республика Башлыгына шул хакта да сорау бирелде.

“Фольклориаданы без ике ел әзерләдек. Билгеле режимны үтәгән шартларда эпидемиологик хәл безгә аны үткәрергә рөхсәт бирде. Ике коллективны кайтарып җибәрергә туры килде, алар – Мәскәүдән һәм Үзбәкстаннан”, – диде Радий Хәбиров.

Республика Башлыгы бу эштә баланс табарга кирәклекне ассызыклады. Бу чараларның уңай ягы да зур булды.

“Уфада балалар Фольклориадасы үткәрү турында карар кабул ителде. 2024 елда беренче балалар Фольклориадасы нәкъ бездә үтәчәк”, – дип билгеләде республика Башлыгы.

Көрәш буенча дөнья чемпионатын үткәрү турында сөйләгәндә төбәк җитәкчесе анда вакциналанган, тест үткән, сәламәт егетләр генә килүен билгеләде. “Ни өчен аларга мөмкинлек бирмәскә?” – диде ул һәм безнең ике егетнең анда чемпион булуын да билгеләп китте.

Радий Хәбиров үзенә карата булган тәнкыйтькә ничек каравы турында да әйтте.

– Мин кешенең ризасызлыгына тыныч карыйм. Мин бүгенге эшчәнлегемне сайлаганда ук моны аңлый идем. Безнең эш белән риза булмаучылар һәрвакыт булачак. Әмма мин беркайчан да кемдер тарафыннан үземә тавыш күтәртмим.

Социаль челтәрләрдә кешене мыскыл итү җиңел. Шуңа да мин анда, социаль челтәрләрне, яратмыйм. Анда алдашу, бер-берсен мыскыл итү адым саен. Әмма безнең халык шунда утыра. Мин анда үземнең эшем турында сөйлим. Социаль челтәрләрне ниндидер бер эш инструменты буларак кабул итәм. Кирәк булган ашыгыч, мөһим мәгълүматны халыкка җиткерү анда җиңелрәк, – диде ул.

• **АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА**

# Тырышларга эш карышмый

**Район үзәгеннән ерак урнашкан Вострецово авылында яшәүче Тамара Зарипова “Агростартап” грантына ия булып, үз эшен башлап җибәрде. Элеккеге ташландык элеватор бинасын алып, ремонтлап, нәселле маллар асрау өчен абзарлар булдырылган. Шушында күптән түгел Пермь краеннан 47 баш герефорд токымлы нәселле таналар алып кайтканнар. Әлегә маллар карантинда.**

– Минем 500 гектар җир мәйданым бар. Мал азыгы культуралары үстерәбез, техник базабыз да бар. Язга чыгу белән хуҗалыкка яңа Беларусь тракторы һәм яңа чапкыч та кайтачак. Грантны мал симертү өчен алдык, киләчәктә нәселле маллар үрчетергә ниятлим, – ди фермер.

Тормыш иптәше Мөнәвәр – аның тугры ярдәмчесе. Өч кызлары күптән үзаллы яши, уллары хәрби училищены тәмамлый, ә төпчек кызлары 10нчы сыйныфта белем ала. Бу гаиләнең тормышларына шатлык өстәп, оныклары да үсеп килә. Тамара һәм Мөнәвәр Зариповлар тормышта булган төрле хәлләрне көлеп искә ала. Аларның көр күңеллелеге, эшсөярлеге, оптимист булуына хәйран калырлык.

– Мин – авыл малае. Әтиәнием дә гомер буе колхозда тир түктеләр. Фермерлык белән шөгыльләнүем акча өчен генә түгел, ә күңел таләбе ул. Җирне яратам һәм аны ташларга җыенмыйм, – ди гаилә башлыгы. Зариповлар маллар кайтуга кыш ашатып чыгарлык азык та әзерләгәннәр. 700 рулон печән ферма янындагы абзар эченә кертеп өелгән, фураж да җитәрлек күләмдә әзер. Биредә крестьян-фермер хуҗалыгы оештырылгач, ике кешегә эш урыны да булдырылган. Әлеге хуҗалыкта бер механизатор һәм бер терлекче көч сала. Эш хакы да авыл җирендә ярыйсы– көне мең сум белән исәпләнеп бара.

**Гөлназ ХУҖИНА.**



# Чаралардан читтә калмагыз!

**6 гыйнварда** «Сабантуй» мәйданында чаңгы буенча ГТО нормаларын тапшыру була, **11.00 сәгатьтә** башлана.

**7 гыйнварда** Яшьләр үзәге территориясендә ачык һавада уеннар – «Кышкы эстафета» оештырыла;

**11.00 сәгатьтә** өченче санлы мәктәп катогында яшьләр арасында хоккей буенча турнир үтә;

**19.00 сәгатьтән** «Океан» бассейны янындагы катокта тимераякта массакүләм шуу, конкурслар үткәрелә.

**8 гыйнварда 10.00 сәгатьтә** үзәк буада кышын балык каптыру буенча ярыш була;

**11.00 сәгатьтә** беренче санлы мәктәпнең күпфункцияле спорт мәйданчыгында «Кышкы футбол» турниры үтә;

**11.00 сәгатьтә** «Океан» бассейны янындагы катокта мәктәп яшендәге балалар өчен киез итекләрдә хоккей була.

**9 гыйнварда 11.00 сәгатьтә** «Сабантуй» мәйданында хезмәт коллективлары арасында чаңгы ярышы оештырыла.

• БҮГЕН РЕСПУБЛИКАДА



# Башкортстанда 2022 елның иң мөһим дүрт вакыйгасы

*Аларны мөһим эшләр календарена теркибез*

## ОЛИМПИАДА

**Кайчан: 24нче кышкы Олимпия уеннары 2022 елның 4-20 февралендә Пекинда узачак.**

Ни өчен бу мөһим: Русия җыелма командасы дәүләт флагыннан һәм гимннан башка чыгыш ясаячак, әмма бу хәл һич кенә дә спортчыларыбызга булган хөрмәт һәм сөюне киметми. Җыелма командаларга кандидатларның алдан төзелгән исемлегенә Башкортстаннан 25 спортчы керде. Аларның 11е – хатын-кызлар хоккее вәкилләре һәм бер спортчы – ирләр командасында, бу – Михаил Науменков. Башлангыч исемлектә шулай ук алты бобслеист, биатлончылар Антон Бабиков, Эдуард Латыйпов, ике төрдә ярышчы Эрнест Яхин һәм сноубордчы Елизавета Салихова бар.

Әлегә ахыргы исемлек юк. Ахыргы исемлекне Шорт-трек буенча Русия җыелма командасының тренерлар штабы гына билгеләде. Ил җыелма командасы составына танылган Уфа шорт-трекчысы – 31 яшьлек Семен Елистратов керде. Аның исәбендә 2014 елда Сочида узган Уеннарда яулаган алтын медаль һәм 2018 елда Пхенчхандагы Олимпиадада яулаган бронза медаль бар.

Кызыклы факт – Кытай башкаласы 2008 елда Олимпиаданы кабул иткән иде инде. Пекин кышкы һәм җәйге Олимпия уеннарын үзендә кабул итүче беренче шәһәр булачак.

## АПИМОНДИЯ

**Кайчан: 2022 елның 5-10 сентябре.**

Ни өчен бу мөһим: 1971 елда Бөтендөнья Апимондия конгрессы Мәскәүдә узды һәм анда катнашучыларның барысында да бу чара турында иң җылы истәлекләр саклана. 50 елдан соң Апимондия конгрессы кабаттан Русиягә әйләнеп кайта һәм Русиянең баллы төбәгендә – Башкортстан Республикасында узачак. Чаралар 2021 елда ук узарга тиеш иде, ләкин коронавирус белән бәйле хәл аркасында күчерелде.

«Апимондия» халыкара ассоциациясе дөньяның 82 иленнән 120ләп умартачылар ассоциациясен берләштерә. Уфага аларның күпмесе киләчәге әлегә билгеле түгел, мотлак берничә мең кеше булыр, дияргә кирәк.

«Апимондия» – галимнәр һәм профессионаллар тәҗрибә уртаклаша, проблемаларны хәл итү юллары турында фикер алыша, бал җитештерү һәм эшкәртү, кортларны тоту һәм дәвалау технологияләре белән бүлешә торган дөнья мәйданчыгы. Мәсәлән, соңгы форум узган Монреальдә пестицидларның бал кортларына һәм аларның селекциясенә йогынтысы турында фикер алыштылар. Мөгаен, Уфадагы конгресс өчен дә бу мәсьәләләр актуаль булыр.

## ВОЛЕЙБОЛ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ

**Кайчан: 2022 елның 26 августыннан 11 сентябренә кадәр ун шәһәрдә – Уфа, Мәскәү, Санкт-Петербург, Калининград, Ярославль, Казан, Екатеринбург, Новосибирск, Красноярск һәм Кемерово шәһәрләрендә узачак.**

Ни өчен бу мөһим: Уфаның волейбол буенча зур халыкара ярышларны кабул иткәне булды, әмма мондый дәрәҗәдәге ярышлар беренче тапкыр узачак. «Уфа-Арена»дан трансляцияләрне бөтен дөнья буенча йөзләгән канал күрсәтәчәк.

Жирәбә нәтиҗәләре буенча Уфада төркем этабы уеннарын Словения, Германия, Франция һәм Камерун милли җыелма командалары үткәрәчәк. Уфа матчларына билетлар tickets.volley.ru сайтында сатыла да инде. Билет бәяләре 400 сумнан 8000 сумга кадәр. Эпидемиологик хәл катлаулы булу сәбәпле, билетлар урыннарсыз сатыла. Кем кайда утырачагын, нәтиҗәдә, махсус программа ярдәмендә хәл итәчәкләр.

Оештыручылар Русиянең һәр шәһәре өчен аерым бизәкләр эшләгән. Башкортстан башкаласын традицион рәвештә Салават Юлаев һәйкәле һәм Лалә-Тюльпан мәчете чагылдырачак. Ә чемпионатның төп талисманы итеп халык тавыш бирүе нәтиҗәләре буенча Тигроша юлбарысы билгеләнде.

## ВАКЦИНАЛАУНЫ ТӘМАМЛАУ


**Кайчан: никадәр тизрәк, шулкадәр яхшырак.**

Ни өчен бу мөһим: 2020 елда без вакцинаның бөтен сынауларны үтүен һәм һәркем өчен аны кадату мөмкинлеге барлыкка килүен көттек. 2021 елда куркуыбызны һәм вакцинаның зыяны турындагы «куркыныч сүзләрне», имеш-мимешләрне җиңдек (Аларның берсе дә расланмады. Киресенчә, дөньяның алдынгы фәнни журналлары «Спутник»ны нәтиҗәле һәм хәвефсез дип таныды). 2022 елда төп бурыч – беренчегә вакциналауны тәмамлау һәм ревакциналана башлау. Бары тик шул очракта гына күмәк иммунитет барлыкка киләчәк һәм коронавирус хәзерге грипп кебек сезонлы чиргә әвереләчәк.

Ел нәтиҗәләре буенча әңгәмәсендә республика Башлыгы Радий Хәбиров белдерүенчә, безне 2,2 миллион кешенең вакциналануы берникадәр тынычландыра һәм көчлерәк итә. Шул ук вакытта күмәк иммунитетка ирешү өчен 2,45 миллион кешенең вакциналануы кирәк. Ревакциналанучылар саны да арта. «Мин инде дүрт тапкыр вакциналандым, чөнки башкача авырырга теләмим, моның нинди нәтиҗәләргә китерүен яхшы беләм. Минем өйдә мотивациям бар – кечкенә балалар. Мин сәламәт булырга тиеш», – диде ул.

Материалларны «Башкортстан Республикасы» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе редакциясе әзерләде.
Язмалар буенча тәкъдимнәрегезне axmetshina.v@rbsmi.ru адресына җибәрегез, телефон: (347) 272-92-61.

# Хезмәте авыр булса да, баш ими



Фәдил Шәрәфгалиев хезмәт юлын 1994 елда элеккеге “Правда” колхозында гади колхозчы булып башлап, бөтен гомерен туган районының авыл хуҗалыгына багышлый. Егерме бер ел буена биредә хезмәтен салгач, “Урожай” хуҗалыгында механизатор булып эшкә урнаша. Фәдил дә хезмәттәшләре белән бергә басучылык һәм терлекчелек тармагын үстерүгә зур өлеш кертә, хезмәт җитештерүчәнлегенең югары булуын һәм авыл хуҗалыгы техникасының көйле эшләвен тәэмин итә.

Агымдагы елда Т-150К тракторын йөгәнли. Зур практик тәҗрибә ярдәмендә ул заманча авыл хуҗалыгы техникасын һәм яңа технологияләрне уңышлы үзләштерә, һәм, иң мөһиме, үз тәҗрибәсен яшь белгечләргә тапшыра. Хуҗалыкта эшләгән дәвердә Фәдил Фәнил улы үзен чын профессионал, грамоталы һәм җаваплы хезмәткәр булarak танытты. Иртә яздан көзге кыр эшләре тәмамланганчы ул бөртекле һәм азык культуралары чәчүдә, терлек азыгы әзерләүдә һәм үстерелгән уңышны җыеп алуда актив катнаша. Югары җитештерү күрсәткечләренә ирешүе өчен һәм Авыл хуҗалыгы хезмәткәре көне уңаеннан Фәдил Фәнил улы Башкортстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

**Гөлназ ХУҖИНА.**

**Извещение о месте и порядке ознакомления с проектом межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей**

Заказчиком работ по подготовке проекта межевания является Вальмиев Ильфир Аслямович, почтовый адрес: 452967, РБ, Бураевский р-н, д. Старокарагушево, ул. Мира, д. 12, тел.: 89825026930.

Проект межевания подготовил кадастровый инженер Гарифулин Марат Ринатович, номер квалификационного аттестата 02-16-1401. Почтовый адрес: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, эл. почта: garifulin1986@yandex.ru, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Земельный участок выделяется в счет земельных долей в праве общей долевой собственности из исходного земельного участка с кадастровым номером 02:17:000000:168, адрес (местоположение): РБ, Бураевский район, Кашкалевский с/с.

С проектом межевания можно ознакомиться у заказчика работ – Вальмиева Ильфира Аслямовича, адрес: РБ, Бураевский р-н, д. Старокарагушево, ул. Мира, д. 12, тел.: 89825026930 или у кадастрового инженера по адресу: РБ, Бураевский район, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Предметом согласования являются размер и местоположение границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка.

Предложения о доработке проекта межевания земельного участка, обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ в счет земельных долей земельного участка по проекту межевания следует вручить или направить в течение 30 дней со дня опубликования настоящего извещения по адресу: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106 и в Филиал ФГБУ (ФКП Росреестра) по Республике Башкортостан по адресу: 450059, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50 лет СССР, д. 30/5. Реклама

• РУХЫЛБАЯН ХӘЙДӘРОВНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

# Гомер юлы – тарих битләре



**Рухылбаян Хәйдәров икенче рәттә сулдан дүртенче.**

1973 елның апрель азаклары. Басуларда язгы кыр эшләре бара. Чәчүнең иң кызган чагы. Ул вакытларда күрше хуҗалыклар – колхозлар малчылык, игенчелек һәм башка өлкәләрдә үзара ярышалар иде. 1 майны күп кенә хуҗалыклар чәчүне төгәлләп каршы алырга чын-чыннан бәйге оештырдылар. Ни гаҗәп “Мир” һәм “Волга” колхозлары арасында волгалылар чәчүне районда беренчеләрдән булып төгәлләделәр. Район гәзите (ул вакытта “Ленин байрагы” дип атала иде) “Волга” колхозы хезмәтен югары бәһалап, кызыл хәрефләр белән махсус бит бирде.

Район комсомол комитетында эшләгән мәл. Бер комсомол эшмәкәренә 29 апрельдә ЗАГСка барып туйлар үткәрергә кирәк иде. Әйбәт машиналардан саналган “Волга” автомобиле КПСС райкомының беренче секретаре Р.Ш.Хәйдәров карамагында гына. Тантанага машина сорап, аның янына юнәлдем. Әлбәттә, гафу үтендем, кызу чәчү өсте бит. Ә Рухылбаян Шәйхлислам улы проблеманы тиз хәл итте.

– Иптәш Нуриев, гаилә корып, яңа тормыш башлаган яшьләр өчен чәчү дә, урак өсте дә тоткарлык түгел. Сезгә миннән бүләк – сезнең карамакка ике көнгә “Волга”, – диде.

Ә бит ул чорларда районда 19 колхоз булып, 100гә якын авыл бар иде. Җитәкчеләр тәүлек әйләнәсенә хуҗалыклардан кайтып керәлмәделәр. Басуларны ашларга кирәк, техника даими сафта булырга тиеш, ягулык-майлау материаллары гына күпме кирәк, кадрлар хәзерләү һәрчак беренче планда. Һәр авылда диярлек терлекчелек фермалары, алардагы сыер, сарык, кош-корт һәрчак меңнәрчә саннар белән исәпләнде.

Әйе, Рухылбаян Шәйхлислам улы районыбызга район партия комитетының беренче секретаре булып ныклы хәзерлек белән килде дип ышанычлы әйтергә җирлек бар. Районыбызга хәтсез мактаулы шәхесләр биргән Колай авылында 1922 елның 3 гыйнварында дөньяга аваз сала ул. Бөре педагогик уку йортын уңышлы тәмамлап, диплом алганнан соң, 1940 елда Совет Армиясе сафларына алына. Ныклы хезмәт чыныгуы алган якташыбыз Япония империалистларына каршы көрәштә катнаша. Туган якларына 1946 елда гына кайта ала. Солдат киемнәрен салганнан соң Бөре район Советында мәдәни-агарту инспекторы булып вазыйфа ала. Аннан тагын чираттагы белем баскычлары: 1952-1954 елларда Югары партия мәктәбендә төпле һөнәр үзләштерә. Аннан соң республикабызның икенче башкаласы Стәрлетамак шәһәренең КПСС район комитетында инструктор йөген тарта. 1954 елда партиянең Башкортстан өлкә комитетына инструктор итеп үрләтелә. Шул ук елны кабат Бөре шәһәренә кайта. Бу юлы инде Рухылбаян Шәйхлислам улы партиянең район комитеты секретаре итеп билгеләнә.

Калган гомер юллары лаеклы ялга чыкканчы туган Борай районында үтә: 1962-1964 елларда Борай авыл хуҗалыгы идарәлегенең партия комитеты секретаре, 1965 елдан 17 ел дәвамында КПССның Борай район комитетының беренче секретаре.

Намуслы хезмәте югары дәрәҗәдә бәһалана килде аның. БАССР Югары Советының 7, 8, 9 чакырылыш депутаты булды, 1976 елда КПССның XXV съезды делегаты булып сайланды. Ике тапкыр Хезмәт кызыл байрагы ордены белән бүләкләнде, алты медаль кавалеры.

Ул район белән ике дистә елга якын идарә иткән чорда районыбыз чын мәгънәсендә төзелеш мәйданына әверелгән иде. Һәр авылда диярлек урта һәм башка мәктәпләр калкып чыкты, мәдәният йортлары балкыды. Заманында республикада гына түгел Русия күләмендә киң танылу алган район колхозара төзелеш оешмасы, “Сельхозтехника”, “Сельхозхимия” коллективлары белән әле булса горурланабыз. Кызганыч, әлбәттә, бүген аларның исемнәре райондашларыбызның бары хәтер янчыгында.

Партия Үзәк Комитеты белән Н.С.Хрущев җитәкчелек иткән дәвердә илебездә кукуруз үстерү алгы планга куелган иде. Район да сынатмады. “Родина” колхозыннан тракторчы Мөдәрис Даянов бу өлкәдә әллә күпме үрләр яулап, КПССның чираттагы съездында делегат, Ленин ордены кавалеры булды. Игенчеләр ярышында башта Киров исемендәге, аннан Мәгъдән исемендәге колхозларның данлыклы комбайнчысы Илүс Вахитов Мәскәүдә ВДНХда катнашып “Москвич” машинасы белән бүләкләнде.

Ә күпме урта звено кадрлары, җитәкчеләр дәрәҗәле исемнәргә лаек булдылар. Аларның һәрберсе район партия комитетының, аның беренче секретаре Рухылбаян Хәйдәровның көндәлек игътибар үзәгендә иде.

Рухылбаян Шәйхлислам улы тормыш иптәше Валентина Петровна белән тигез тормышта яшәп, уллары Фәритне олы юлга аяк бастырдылар. Ул бик озак еллар Дүртөйле шәһәрендә хәрби комиссар булып эшләде.

**Фидаил НУРИЕВ,**
**хезмәт ветераны.**

–Миңа дүрт дистә елга кадәр башта Вострецов исемендәге, аннан Ленин исемендәге колхозлар белән җитәкчелек итәргә насыйп булды. Мактанырга җыенмыйм, әмма ике хуҗалык та һәрчак игенчелек өлкәсендә дә, терлекчелектә дә район күләмендә һәрчак алдынгылар сафында бардылар.

Бәхәссез, без бу уңышлар, җиңүләрдә партия, район комитетын җитәкләгән Рухылбаян Хәйдәровның ышанычлы кулларын, олы оештыру сәләтен даими тоеп килдек.

Ә күпме төзелеш эшләре башкарылды. Безнең Ленин исемендәге хуҗалыкны гына алыйк. Катнашазык комбинаты тиз арада сафка керде. Район мәдәният йортыннан һич калышмаган клуб салынды, Бадракта урта мәктәп укучыларны кабул итте. Безнең күрше колхозыбыз булган “Искра” хуҗалыгында 12 мең башка исәпләнгән дуңгызчылык комплексы төзелде. Аны сафка бастыруда ул вакытта хәтта чит ил студентлары да катнашты.

**Рәфит НӘҖМЕТДИНОВ, РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, БАССРның атказанган агрономы, IV Бөтенсоюз колхозчылар съезды делегаты.**

***

–Район җитәкчесе булган Рухылбаян Шәйхлислам улына без, мәгариф өлкәсе кешеләре, аеруча рәхмәтлебез. Нәкъ ул җитәкчелек иткән дәвердә районда ел саен урта, сигезьеллык, башлангыч мәктәпләр ачылу гадәти күренеш иде. Укытучыларның, тәрбиячеләрнең һәр бәйрәмнәрендә хезмәтләре югары бәһаланды.

Баян Шәйхлислам улы укучылар өчен оештырылган чараларда олы теләк белән катнаша иде. Заманында элеккеге Танып елгасы үзәгендәге ГЭС янында урнашкан пионерлар лагерен ачуда да иң активлык күрсәткән шәхес булды ул. Ә инде укытучылар конференциясендәге тирән эчтәлекле чыгышлары әле дә хәтердә саклана.

Шуны да телгә алу урынлы булыр: Рухылбаян исеме гарәпчәдән Алла рухы, ачыклык рухы дип тәрҗемә ителә. Ифрат дөрес.

**Фәнис АБАЗОВ, БРның атказанган мәгариф хезмәткәре, СССР мәгариф отличнигы, педагогик фәннәр докторы, профессор.**

***

–Рухылбаян Шәйхлислам улы белән минем хезмәт юллары заманында тыгыз бәйләнеп килде. Мин район комсомолы оешмасын җитәкләгәндә яшьләрнең бүген-иртәгәсе хакында аның хәстәрлеген тоеп эшләдем. Комсомол сафларын лаеклы егет-кызлар белән тулыландыру да аның күз уңаенда булды. Безнең районның иң эре производство оешмаларында, колхоз фермаларында, басу-кырларда комсомол яшьләр отрядлары оештыруны да бик хуп күрде.

Республикада спорт комитетлары, стадионнар төзү алгы планга куелгач, Рухылбаян Шәйхлислам улы әле Борай уртасында уңышлы эшләп килгән стадион проектын, төзелеш өчен финанс чараларын эзләүдә ифрат күп көч салды.

Район үзәгенең Ленин һәм башка урамнарында иске агач йортлар урынына ике катлы, күпфатирлы кирпеч йортлар калкып чыгуы да аның хезмәте.

**Даниф НУРОВ, район комсомол комитетының беренче секретаре, 2нче класслы дәүләт советнигы.**

***

–Өлкән буын яхшы хәтерли – Рухылбаян Шәйхлислам улы район белән җитәкчелек иткән чорда Бораебызның, авылларның йөзе күренеп уңайга үзгәрде. Ул республикада беренчеләрдән булып районда колхозара төзелеш оешмасын төзетте, тора-бара кирпеч һәм тимер-бетон заводлары сафка басып, алар районга гына түгел, күрше төбәкләргә дә хезмәт күрсәтте.

Ә башка өлкәдә төзелешләр күпме булды! Үзәк дәваханәдән тыш авылларда фельдшерлык пунктлары, сәүдә нокталары, көнкүреш хезмәте күрсәтү пунктлары төзелеп, халыкка бәһалап бетергесез хезмәт итте. Районда намус белән эшләгән кешегә олы ихтирам булды.

Аның тууына 100 ел тулу уңаеннан районның бүгенге җитәкчелегенә коммунистлар һәм аны яхшы белгән кешеләр исеменнән безнең мөрәҗәгатьне үтәп, Рухылбаян Шәйхлислам улы Хәйдәровның кабер ташын һәм киртәсен яңарткан өчен рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Фәнил ИБРАҺИМОВ, КПРФның урындагы бүлекчәсе җитәкчесе, БРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.**

• ЮБИЛЯР

# Ялкынлы тормыш

Фидаил Сафа улы Нуриев хакында язар алдыннан, ирексездән аның әнисе Сөгъдә апаны исә алдым. Апаның башка күпләрдән аерым бер гадәте бар иде. Ул – гадәттән тыш уңганлык. Аның бу сыйфатын күрсәтер өчен берничә мисал китереп китәм.

...Без иртәнге тугыз сәгатьтә Әҗәк авылына машинада командировка җилдерәбез. Асфальт юлдан каршыга бидрә тоткан апа килә.

– Сөгъдә апа, каян болай Борайга кайтып киләсең?

– Җир җиләгенә барган идем, менә бер бидрә җыеп алдым әле. Төштән соң янә бер рейс ясыйсы бар.

– Җиләк өлгергәндәмени әле?

– Инде, әллә кайчан пеште ул...

Икенче бер вакыт, аларга апаның өенә чыгабыз. Сөгъдә апа күтәрмәдә каен миллеге бәйләп утыра.

– Миллекне кайчан җыйдың?

– Өченче көн. Менә бәйләргә җитешә алмадым әле.

Без, машиналы кешеләр, яфрак картая башлагач мунча миллеге әзерли башлыйбыз, җитешә алмыйбыз. Ә ул 5-6 чакрым җәяү үтеп, миллекне әзерләп куйган була.

Шаккатмалы хәл – борайлылар кыяр утыртканчы, без инде Сөгъдә апаның кыярын тәмлибез, башка җимешләре белән дә шулай.

Менә шушы сыйфатлар аның улы Фидаилгә дә хас.

– Мин радиотапшырулар әзерлим, иртәнге якта КПССның 1 секретаре Рухылбаян Хәйдәров иртәнге 7 сәгатьтә аны радио аша тыңлап, эшкә китә иде, – дип искә ала Фидаил Сафа улы, ул радиотапшырулар редакциясе редакторы булып эшләгән чакларын шулай искә төшереп ала иде.

Үзем белгәндә, Фидаил Нуриев ВЛКСМ райкомының оештыру бүлеге мөдире булды. Райкомның ул вакытта кем беренче, кем икенче секретаре булганы хәтердә калмаган, әмма Фидаил Сафа улының яшьләр белән күп эшләгәнен яхшы хәтерлим. Комсомол прожекторы, яшьләрнең оператив отряд члены булып көн дә кичен дежурга чыгулары искә алам. Фидаил хәйләкәр иде. Кайсы егетнең кайсы кызга күңеле төшкәнен белеп, аларны бергә төнгелеккә дежурга куя иде.

Кичәге сатучылар, ашханәчеләр гафу итсен, яшьләрнең оператив отрядлары көн аралаш диярлек сәүдә, гомумтуклану урыннарына рейдка чыгалар иде. Максат – сатып алучыларны алдамыйлармы, чисталыкка игътибар итәләрме, яшүсмерләргә аракы сатылмавын белү. Ә рейд нәтиҗәләре "Алга" гәзите битләрендә күренә, гаепплеләргә чара күрү өчен мәкалә райпо рәисенә җибәрелә. Тегеләр исә, рейд нәтиҗәләре буенча чара күрдек, дип җавап бирәләр. Чара күрелгәнме юкмы, анысын Ходай белә, әмма халык гәзитне яратып укый, тиражы арта.

Оештыру бүлеге мөдире Фидаил Нуриевның җәмәгать белән бергә эшләгән зур чарасы – Яшьләр көнен үткәрүе булды. Бүген моны бары күпләр әкият итеп кабул итәргә мөмкин, ә алар чыннан да булды.

Яшьләр көне районда Танып елгасы буенда меңләгән кеше катнашлыгында район сабантуеннан зуррак масштабта оештырыла иде, бу бәйрәм уеннар, ярышлар, бүләкләр белән үтеп, анда бар түрәләр дә катнашалар иде. Фидаил комсомолдан киткәч, Яшьләр көне тыйнаграк, ябык бүлмәләрдә үтә башлады.

Фидаилнең байтак гомере журналист буларак, "Алга" район гәзитендә үтте. 1975 елда ул редакциянең хатлар бүлеге мөдире булып эшли башлады. Миңа аның документлар белән оста эш итүе, профком рәисе буларак типография эшчеләренең разрядларын күтәрү, корреспондентларның стажына өстәмә түләүне кертеп, хезмәт хакларын арттыруы хәтердә калган.

Ул елларда гәзиттә тәнкыйть материаллары еш басыла иде. Фидаил Нуриев исә ул жанрда оста эшләде. Бигрәк тә фельетон жанрын мул куллана иде. Теге яки бу оешмада, учреждениедәге кимчелекләрне күреп, аларны халыкка җиткерүдә аңардан да өлгеррәге булмагандыр.

Шуны да әйтү җитә: бер тәнкыйть мәкаләсе язган өчен аның фатирының тәрәзәсен таш бәреп ваттылар. Ә инде түрәләр, җитәкчеләр тарафыннан җәберләгәннәрен санап бетерерлек түгел.

Фидаил Нуриевның инициативалы икәнен КПСС райкомында күрделәр һәм аңа кино челтәре директоры вазыйфасын тәкъдим иттеләр. Моңа сәбәп тә бар иде, практикада моңарчы кайбер элекке җитәкчеләргә директор вазыйфасын биреп карасалар да, болар әллә ни уңышка ирешә алмадылар. Алар, элеккечә, команда бирсәң, нәтиҗә була икән, дип фикер йөрттеләр. Ә кино өлкәсендә эшләргә, күп һәм яхшы фильмнар табарга, аларны халыкка тәкъдим итә белергә кирәк иде. Нуриев эшли башлагач, киноны күбрәк авылларга тараттылар, киноустановкалар саны артты, урындагы җитәкчеләр белән уртак тел табылды, кино керемле өлкәгә әйләнде. Бигрәк тә авыл хуҗалыгы хакында кинолар артты, мәктәпләргә, пионер лагерьларына фильмнар керде, халык яраткан һинд кинолары еш куелды. Кинога билет алу өчен чиратлар җыелды. Нәтиҗәдә, Борай кинофикациясе Башкортстанда алдынгы урынга чыкты, дәрәҗәле исемнәр дә килде.

Борайда хәзерге заман кинотеатры төзү көн кадагына керде. Фидаил Нуриев бу идеяне тормышка ашыру өчен күп эшләде. Яңа театрга урын табу, иске йортларны сүтеп, хуҗаларына яңа фатирлар табу һәм башкалар эзләнүне сорады. Ул вакыттагы районны җитәкләгән Мәгънәви Шакиров, төзелеш буенча урынбасары Рамил Вяльшин һәм башкалар бик тырыштылар.

Яңа кинотеатр республика авылларында иң зуры һәм яхшысы килеп чыкты. Бу бина бүген дә дистәләрчә учреждениегә уңайлы эш урыны булып тора, кинотеатр ролен дә үти.

Фидаил Сафа улының үзгәрешләр чорында район хакимиятендә эшләгәнен дә искә алырга кирәк. Бу, кем әйтмешли, сүтеп кору чорында район белән җитәкчелек итүнең яңа ысуллар куллана башлау чоры иде.

"Алга" редакциясендә яңадан бергә эшли башладык. Биредә дә аның инициативалылыгы, дөреслекне күзгә карап әйтә белүе дә бик ярап куйды.

75 яшен тутырып килгән Фидаил Сафа улы Нуриевта инициатива әле җитәрлек. Комсомол юбилейларын оештырсынмы, журналист эшчәнлеген дәвам итсенме, КПРФ әгъзасы буларак төрле чараларда кайнасынмы, ул катнашкан һәр чара халык белән истә калырлык итеп үтә.

Аның хакында күп язарга мөмкин, алган бүләкләрен дә, башкарган эшләрен колачлап бетерерлек түгел. Халык абруен яулаган медик Венера ханым белән гаҗәп акыллы кызлары Гөлназ, оныклары белән горурланып яшиләр алар. Алда да шулай дәвам итсен.

**Рәзиф ЗИЯТДИНОВ,**
**редакциянең ветераннар советы рәисе.**

# Авылның ак әбисе

**Бөек Ватан сугышы башланганда кечкенәдән зур сынаулар үткән сабыйлар хәзер инде өлкән яшьтәге кешеләр. Бүгенге көндә алар тыныч тормышта, балалары, оныклары тәрбиясендә яшәүләренә сөенеп, изге догалар укып, бәхетле картлык кичерә.**

Иске Бикмәт авылында яшәүче хезмәт ветераны, авылның ак әбисе Гөлхая Ганиева 90 ел элек матур табигатьле, ямьле урман эчендә урнашкан Яңа Тукран авылында Маһирә һәм Хаҗимөхәммәт Усмановларның ишле гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә.

Аның бала чагы, кызганычка каршы, сугыш чорына туры килә. Бөек Ватан сугышы башлангач, бөтен дөнья хәстәре үсмер малайлар, кызлар, әбибабайлар, тол хатыннар кулына кала. Биш баласы белән тол калган Маһирәгә дә бик авыр була.



Авырлыкларга бирешмичә, балаларына тиешле тәрбия бирә, хезмәткә өйрәтеп үстерә. Сугыш чорында эвакуацияләнгән бер урыс гаиләсен аларга яшәргә кертәләр. Гөлхая ул гаилә белән аралашып урыс теленә өйрәнә.

Әнисе янында йөреп төрле эшләргә өйрәнгән кыз, унсигез яше тулгач, Свердловск шәһәренә эш эзләп чыгып китә һәм кара металл заводына эшкә урнаша.

– Биредә эшләп, 1200 сум эш хакы алгач, шатлыгым эчемә сыймады. Әнкәйләргә авылга күчтәнәчләр, киемнәр сатып алып, посылка җибәрдем. Монда эшкә килүемнең бер максаты бар иде: үземә тегү машинасы алу хыялы. Хыялыма ирештем, тегү машиналы булдым, бирнәләр җыйгач, отпускка авылга кайттым. Иске Бикмәт авылында яшәүче Әлфия туганыма кунакка килдем. Яшь чак бит инде, клубка кино карарга чыктык, аннары вечерга калдык. Шунда миңа Мөхәмәдия исемле бер егет күз салган булган. Янымда туктаусыз бөтерелсә дә, мин аңа игътибар итмичә, сер бирмичә кайтып киттем. Күрше авыл егете икенче көнне мине авылга эзләп төшкән, шуннан танышып, сөйләшеп киттек,–дип сөйләде яшьлек елларын искә төшереп әбекәй.

Гөлхая белән Мөхәмәдия 1955 елда кавышып, матур гаилә корып, ике бала үстерәләр. Гаилә башлыгы колхозда механизатор, ә Гөлхая апа төрле эштә көч сала. Чөгендер, мәк утау, печән чабу, амбар алдында эшләү– болар барысы да аның кулы аша уза. Бу ике уңган 1961 елда матур итеп өй салып чыгалар. Ул вакытта төзелеш материаллары булмау сәбәпле, Гөлхая апа үзе балчык алып кайтып, кирпеч суга. Кичләрен туннар, күлмәкләр тегеп, фуфайкалар сырып, палас сугып гомер итә. Шулай ук авылда пима басучы буларак та билгеле була. Ул баскан йомшак, аякка ипле, матур пималарны авылдашлары һәм күрше-тирә як халкы яратып, суык кыш көннәрендә аңа рәхмәт сүзләре әйтеп, сәламәтлек теләп кигәндер.

Бар эшнең дә серенә төшенеп эшли ул. Ә иң яраткан һөнәре китап уку була. Көндез колхоз эшендә, кичен кул эшләре эшләп арыганнарын, төннәрен китап укып бетергән. 1976 елда яңадан өй салгач, моржасын үзе чыгара. Шулкадәр уңайлы мич бүгенге көндә дә Гөлхая әбинең өен җылытып утыра. Ярты гасырдан артык ел бергә тату, бер-берсен аңлашып яшиләр алар тормыш иптәше белән. Чыннан да, шул гомер эчендә ни генә кичермәгән бу ике җан. 53 ел буена шатлыклары да, кайгылары да уртак булган. Көнне-төнгә ялгап, ару-талуны белмичә икәүләп колхозда фидакарь хезмәт салалар. Еллар сукмагыннан горур атлап, сикәлтәле юлдан абынмый хәтсез гомер үтеп тә киткән.

Кызы гүр иясе булгач, Гөлхая апа оныгы белән яши. Минем ярдәмчем, иптәшем, дип шатлана ул оныгына карап.

**Гөлназ ХУҖИНА.**

# Үз эшенең остасы

**Бөек галим И.Павлов “Табиб кешене дәваласа, ветеринар бөтен кешелекне дәвалый” дип юкка гына әйтмәгән. Авыл хуҗалыгы тармагында ветеринария хезмәткәрләренең роле зурдан. Нәкъ менә аларның эшчәнлеге райондагы эпизоотик хәлнең иминлеген тәэмин итә. Терлекләрне, кош-кортларны дәвалаучы, кешеләрнең сәламәтлеген саклау сагында торучы һәм азык-төлек продуктларының чисталыгы өчен җавап бирүче дә ветеринарлар.**



Районда хайваннар авыруларын кисәтү һәм дәвалау буенча Илмира Нигъмәтуллина бу эштә 20 елдан артык эшли. Башкорт дәүләт аграр университетында ветеринария табибы һөнәрен алып, район ветеринария лабораториясендә ветеринария санитары вазыйфасында хезмәт юлын башлый ул. 2001 елның сентябрендә Илмира Ринат кызы лаборант итеп, ә бер елдан соң ветеринария табибы – серолог итеп күчерелә. Югары профессиональлеге, җаваплылыгы белән аерылып торган яшь белгеч тәүдә Ваныш ветеринария пункты мөдире, аннары Таңатарда шушы ук вазыйфаны башкара, аннан Чалкак ветеринария участогы мөдире итеп күчерелә. Белемле, тәҗрибәле һәм аларны практикада куллана белгән Илмираны 2018 елда район ветеринария станциясенә әйдәп баручы ветеринария табибы итеп билгелиләр. Менә ике ел инде эпизоотиягә каршы отряд начальнигы вазыйфасын уңышлы башкара ул. Илмира Нигъмәтуллина авыл хуҗалыгы терлекләре авыруын кисәтүнең һәм дәвалауның эпизоотик иминлеген тәэмин итүгә һәм ветеринария хезмәте күрсәтүне яхшыртуга юнәлдерелгән яңа методларны кертү буенча да зур эш башкара. Мөгезле эре терлекләрнең сакланышын арттыру максатыннан кышкы абзарда бозауларны карау буенча да эш алып бара. Илмира Ринат кызы кайда гына эшләсә дә, үзен оста оештыручы, үз эшен белүче белгеч итеп күрсәтә. Яраткан һөнәреннән тыш Илмира районда узган мәдәни-массакүләм чараларда да актив катнаша.

**Гөлназ ХУҖИНА.**

# Фотоконкурс җиңүчеләре

**10 декабрьдән 26 сына кадәр гәзитнең ВКонтакте төркемендә «Мин урман чибәрен бизәдем» дигән балалар фотоконкурсы узды. Нәтиҗәләр буенча 1 урынны Руслан Хуҗин алды, 2 урынны Дилә Муллина, 3 урынны Марсель һәм Редаль Зәйдуллиннар яулады. Вәгъдә ителгәнчә, катнашучыларның фотосурәтләрен басабыз.**







# Интерактив музей проекты

**Башкортстанда «Авыл мәктәпләре тарихы» интерактив музей экспозициясе барлыкка киләчәк.**

Проект мәктәп музейлары фондларының электрон базасын булдырырга мөмкинлек бирәчәк, ул мәктәп музей коллекцияләренә килүчеләрнең киң даирәсенә «Башкортстан Республикасы авыл мәктәпләре тарихы» интерактив музей экспозициясен булдыру буенча проект эшли башлады.

Проект Башкортстан Республикасы Гражданнар җәмгыятенә ярдәм фонды һәм Башкортстан Республикасы Башлыгы грантына «Сәләтле балалар» социальләштерү һәм үсеш үзәге» тарафыннан тормышка ашырыла.

Стратегик тикшеренүләр институты матбугат хезмәтендә хәбәр итүләренчә, проект мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне актив куллануга исәпләнгән. Интерактив музей булдыру челтәрдәге мәгълүмат киңлеген киңәйтәчәк, шулай ук мәктәп музейлары фондларының электрон базасын булдырырга ярдәм итәчәк, ул мәктәп музей коллекцияләренә килүчеләрнең киң даирәсен саклап калуны һәм һәркем файдалана алуны тәэмин итәчәк.


Интерактив картада тулаем белем бирү тарихын һәм аерым алганда һәр мәктәпнең үсеш тарихын күрергә мөмкин булачак.

Интерактив карта – бер ресурста тарихи мәгълүмат җыю ысулы. Мәгълүмат киңлегенең элементы буларак, әлеге карта конкрет территория белән бәйле мәгълүмат чыганакларына арадашчы булып тора, аны теләсә кайсы буын өчен уңайлы итәчәк.

Музей экспозициясендә мәктәп музейлары, республика дәүләт һәм ведомство музейлары коллекцияләреннән экспонатлар, тарихи документлар, фоторәсемнәр һәм башка кызыклы материаллар һәм артефактлар тәкъдим ителәчәк.

• СПОРТ

# Көч беләктә түгел, дисәләр дә...



Сәламәт яшәү рәвеше алып баруга, спорт белән шөгыльләнүгә районда зур игътибар бирелә. Яшьләр дә сәламәт яшәү рәвешен үз итә. 25 декабрь көнне Дүртөйле шәһәрендә пауэрлифтинг (штанганы ятып этәрү) һәм спортның көч төрләре буенча яңа ел турниры узды. Ярышлар берничә төрле үлчәү категориясендә оештырылды. 75 килограмм авырлык категорияләрендә “Һәвәскәрләр. Бицепска штанга күтәрү. Классик” дисциплинада 47,5 килограмм нәтиҗәсе белән Миңле авылы егете, гер спорты буенча район җыелма командасының даими әгъзасы Фәдис Исламов икенче урынны яулады. Шулай ук Фәдис спорт мастерлыгына кандидатлар өчен нормативларны үтәде. Ул диплом һәм медаль белән бүләкләнде.

26 декабрьдә гер спорты буенча Дүртөйле районының беренчелеге үтте. Бирелдә дә Фәдис үзен сынатмады. Ул, ике кулында 24әр килограммлы герләрне 98 тапкыр, ыргылыш күнегүендә 183 тапкыр күтәреп, ярышларның җиңүчесе булды.

Тренер Радик Хәмидуллин билгеләвенчә, гер спорты – ул шәхси спорт төре. Аның белән ныклап шөгыльләнгәндә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә була.

**Зәһинә ИБӘТУЛЛИНА.**








## ЯНВАРЬ

| | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1 | 2 |
| 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
| 31 | | | | | | |

## ФЕВРАЛЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 |
| 28 | | | | | | |

## МАРТ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 |
| 28 | 29 | 30 | 31 | | | |

## АПРЕЛЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 | 2 | 3 |
| 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
| 25 | 26 | 37 | 28 | 29 | 30 | |

## МАЙ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 1 |
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
| 30 | 31 | | | | | |

## ИЮНЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 |
| 27 | 28 | 29 | 30 | | | |



algaburaevo.ru








## ИЮЛЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 | 2 | 3 |
| 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
| 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 |

## АВГУСТ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 |
| 29 | 30 | 31 | | | | |

## СЕНТЯБРЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 | 2 | 3 | 4 |
| 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 |
| 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | | |

## ОКТЯБРЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1 | 2 |
| 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
| 31 | | | | | | |

## НОЯБРЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 |
| 28 | 29 | 30 | | | | |



## ДЕКАБРЬ

| пн | вт | ср | чт | пт | сб | вс |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 | 2 | 3 | 4 |
| 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 |
| 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 | |

# Юлбарыс елы ниләр вәгъдә итә

***Көнчыгыш календаре буенча 2022 ел – Су Юлбарысы елы. Белгечләр аны дөрес каршыларга киңәш итә. Бу очракта бәхет урап узмас. 2022 ел барлык билгеләр өчен дә үзе белән зур үзгәрешләр алып киләчәк. Чөнки елның яклаучысы үзе – актив хайван, шуңа күрә барлык билгеләргә дә активлык күрсәтергә туры киләчәк. Бу бигрәк тә ут һәм һава билгеләренә кагыла.***

**Сәламәтлек**

Юлбарыс елы актив яшәү рәвеше алып баручыларга сәламәтлекләре сизелерлек яхшыруны вәгъдә итә. Ә кемнәр әле икеләнеп тора, алар өчен ел башы – спорт белән шөгыльләнә башлар өчен менә дигән вакыт. Су стихиясе йөрәк һәм юка эчәклек эше өчен җаваплы булганлыктан, яңа елда нәкъ менә шушы органнарга игътибар итәргә кирәк. Элек барлыкка килгән авыруларны җиңеп чыгу мөмкинлеге бар. Юлбарыс елында психологик проблемалары турында белгән кешеләргә аеруча үз сәламәтлекләрен кайгыртырга кирәк булачак.

**Гаилә**

Булачак елда ата-аналарга яшүсмер балалары белән мөнәсәбәтләрне җайга салу мөмкинлеге бар. Юлбарыс үз нәселен бик саклый, шуңа күрә күптәннән авырга кала алмый интегүчеләр өчен яңа ел – иң кулай вакыт.

Өлкән яшьтәге ата-аналар белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, киресенчә, сак булырга кирәк: әгәр дә сез аларга карата игътибарыгызны җитәрлек күрсәтмәсәгез, аралашу шактый начарланырга мөмкин. Бу чорда мөмкин кадәр күбрәк уртак эшләр эшләргә, бергә ял итәргә кирәк.

Шул ук вакытта үзегез турында да онытырга ярамый.

**Мәхәббәт**

Бу елны кияүгә чыгарга һәм баланы мөмкин кадәр тизрәк табарга теләгән кызларга бәхет елмаячак. Әмма теләсә нинди мөнәсәбәтләргә баш белән чумарга кирәкми. Игътибарлырак булырга кирәк, чөнки булачак сөйгән ярыгыз юлбарыс характерлы булырга мөмкин, ягъни саран булырга һәм гаилә башлыгы урыны белән бүлешергә теләмәскә мөмкин. Нәкъ менә шундый ир-атлар Юлбарыс елында хатын-кызлар күңелен аеруча яуларга мөмкин дә инде. Тик беренче тәэсиргә ышанып, алданып калмагыз!

**Карьера**

Юлбарыс елы үзе белән актив һәм уйлап табучан кешеләргә зур карьера үсеше алып киләчәк. Су стихиясе зур үсешкә этәргеч бирә, детальләргә игътибар бирергә, үзең эшләгән юнәлешкә чумарга тәкъдим итә. Шулай ук яңа ел эшчәнлек, һөнәри юнәлешне алыштырырга мөмкинлек бирәчәк. Ә пассив кешеләргә Юлбарыс елында авыр булачак.

**Финанслар**

Юлбарыс – иң юмарт хайван түгел, шуңа күрә финанс дәрәҗәсен күтәрү өчен көрәшергә туры киләчәк. Әмма тырышкан кешеләр өчен уңышлар шактый булачак, акча агымы да сизелерлек артачак. Юлбарыс шактый чыгымнарны хупламый, тик шул ук вакытта гаилә эчендә һәм якын кешеләргә бүләкләр тапшыру яклы.

Шуңа карамастан, 2022 елга астрология фаразы җиңел генә карьера очышы да, финанс хәлен тиз яхшыртуны да вәгъдә итми. Актив һәм хезмәт сөючән белгечләр, мөгаен, теләгәненә ирешер, ә калганнарга авыр туры киләчәк.

Бу ел үз-үзен үстерүгә, психологик халәтен анализлауга, интеллектуаль һәм һөнәри үсешкә зур игътибар бирүчеләр өчен дә яхшы булачак.

## 2022 елга йолдызнамә



**Кучкар**
**21.03-20.04**

Кучкар – ут билгесе, ул үз-үзен тотышы, хистойгылары, тугрылык һәм намуслылык, юмартлык, киң күңеллелек кебек сыйфатлар белән аерылып тора. Бу билге вәкилләренә бик авыр, әлбәттә, аларның «шартлаткыч» характеры да үз ролен уйный. Әмма 2022 ел кучкарлар өчен уңышлы һәм кызыклы вакыйгаларга бай булырга ошаган. Ел дәвамында сәламәтлекләрен һәм физик көчләрен саклау өчен, ут билгесе вәкилләренә Укчылар һәм Арысланнар белән даими спорт залына йөрергә, тукланууларына игътибар итәргә, мөмкин булганча, экзотик ашамлыклар ашамаска, өйдә пешергән ризыкларга өстенлек бирергә, көндәлек физик күнегүләргә сулыш гимнастикасын кертергә киңәш ителә, ул стресстан арынырга ярдәм итәчәк.

Карьерага килгәндә, 2022 ел Кучкарларның иң актив вәкилләренә хезмәт буенча алга китеш вәгъдә итә. Әгәр оешма, предприятие, компаниянең барлык проектларында да актив катнашып, җитәкче белән бәхәскә кермичә, хезмәттәшләрегез – һава билгеләре вәкилләре (Үлчәү, Игезәкләр, Сукоярлар) белән якынайсагыз, әлбәттә, сезне уңыш көтәчәк. Ел башы (февраль-март) – эштә яңа идеяләр һәм тәкъдимнәр белән уртаклашу өчен иң уңайлы вакыт. Әмма артык үҗәт булырга кирәк түгел; әгәр җитәкчелек тәкъдимне шунда ук бәяләмәсә, бераз көтәргә кирәк булачак.

2022 елга Кучкар өчен карьера буенча алга китеш вәгъдә итсә, финанслар ягыннан хәлләр бертөрле генә булмаячак. Бәхет елмайган очракта отышның бер өлешен яхшы эшләргә тотарга кирәк, ул чакта уңыш һәм муллык ел азагына кадәр китмәячәк. Ел ахырында кредитлар һәм займнар алырга киңәш ителми. Җир билгеләре вәкилләренә (Үгезбозау, Кыз, Кәҗәмөгез) бурычка бирмәгез, акчагызны гына түгел, дустанә мөнәсәбәтләрне дә югалту куркынычы бар. Өйгә уңыш һәм финанс иминлеген җәлеп итү өчен билге вәкилләренә ел дәвамында акчаларга сакчыл карашта булырга һәм зур суммага әйберләр сатып алмаска киңәш ителә. 2022 елга йолдызнамәсе март азагы – апрель башында туган Кучкарларга лотереядә зур отыш вәгъдә итә.

2022 ел вәгъдә иткәнчә, Кучкарлар өчен мәхәббәт фронтында тынлык булмаячак. Вакыйгаларга иң бай вакыт июнь-сентябрь айлары булачак. Икенче яртысын тапмаган Кучкарларга үз билгесе вәкилләренә, шулай ук Кәҗәмөгез һәм Укчыларга игътибар итәргә кирәк.



**Үгезбозау**
**21.04-20.05**


Үгезбозауларга Су Юлбарысы елы күп кенә күңелле һәм көтелмәгән вакыйгалар бүләк итәчәк. Яңа танышулар бик зур роль уйнаячак. Язмышның мөһим билгеләрен ычкындырмас өчен, аларның һәрбересенә игътибар итәргә кирәк.

Үгезбозауларның сәламәтлекләре ныклы, тик алар үз яшәү рәвешенә бармак ашау караулары аркасында төрле күңелсезлекләргә дучар булырга мөмкин. Нинди дә булса хроник авырулары булган Үгезбозауларга аларны дәвалауга һәм өзлегүләрне профилактикалауга басым ясарга киңәш ителә. 2022 елда Үгезбозауларга тешләренең торышын игътибар белән күзәтергә киңәш ителә. Бу билге вәкилләренә аеруча ашказаны системасына сакчыл караштa булырга киңәш ителә.

2022 елга йолдызнамәсе Үгезбозауларга үз финансларына игътибарлырак булырга туры киләчәк, дип кисәтә. Бәлки, яңа финанс инструментларына, инвестицияләр, кертемнәр һәм кыйммәтле кәгазьләрне өйрәнергә туры киләчәк. Йолдызлар эре финанс алышбирешләр, аерым алганда, күчемсез милек сатып алуны хупламый.

2022 ел Үгезбозаулар карьерасы таугa барырга тиеш дип фаразлый. Яңа елда Үгезбозауларга хыялланган эшен һәм вазыйфасын алу җиңел булачак, тик аларга югары вазыйфага дәгъва кылыр алдыннан үз көчләрен һәм мөмкинлекләрен җентекләп үлчәргә кирәк.

Яңа 2022 елда Үгезбозауларга элекке мөнәсәбәтләрен калдыру яхшырак булачак. Кинәт кенә зур гаугалар, ыгы-зыгы килеп чыкса да, Үгезбозауларга яры белән аерылышу дөрес карар булмаячак. 2022 елга мәхәббәт йолдызнамәсе кисәткәнчә, Үгезбозаулар партнерларын үпкәләтергә мөмкин, тик соңыннан алар моның өчен бик үкенәчәк. Үпкәләгән яры Үгезбозауга алмашны тиз табачак, шуңа күрә бу адым өчен үкенмәскә мөнәсәбәтләрегезне куркыныч астына куймагыз. Ялгыз Үгезбозауларга бу ел романтик мөнәсәбәтләр бәйләү өчен иң уңайлы ел түгел.



**Игезәкләр**
**21.05-21.06**


Күп кенә Игезәкләр өчен 2022 ел яңа ачышлар елы булырга вәгъдә итә.

2022 елда Игезәкләргә бакытның зур өлешен сәламәтлеккә багышларга кирәк булачак. Бу билгенең нерв системасы алдагы бернichә елда читтән төрле һөҗүмнәргә дучар булды, шуңа күрә хәзер аңа ял итәргә кирәк. Игезәкләргә социаль челтәрләрдә булуны чикләргә, явыз комментарийларны укымаска, туганнары һәм дуслары белән генә аралашырга, кызыклы шөгыль табарга, көнен кимендә ике сәгать саф һавада йөрергә киңәш ителә.

Һаман да үз урынын тапмаган Игезәкләр өчен Су Юлбарысы елы хыялланган эшен табу мөмкинлеге бирәчәк. Бәлки, кайбер кешеләр ачылган вакансия турында хәбәр салыр, яки ерак туганы Игезәкләрнең балачагында күптән онытканн мавыгуын искә төшерер. Бу вак-төякләргә колак салыгыз, алар бик мөһим булырга мөмкин.

Финанс өлкәсендә йолдызлар Игезәкләргә эре сатып алуларны планлаштырырга киңәш итә. 2022 елга финанс йолдызнамәсе тәкъдим иткәнчә, турыдан-туры акча белән эшләүче, банк хезмәткәрләре, финанс консультантлары, бухгалтер Игезәкләргә бик игътибарлы булырга кирәк, бигрәк тә ел башында.

2022 ел Игезәкләрнең мәхәббәт мөнәсәбәтләрендә тынычлык булачак. Бу йолдызнамә вәкилләре алдагы елны тыныч һәм үлчәмле итеп үткәрәчәкләр, зур ыгы-зыгылар артта калачак. Ялгыз Игезәкләргә үзләре өстендә эшләргә – спорт залына йөрергә, бизәнү курсларына язылырга, гомумән, матурланырга киңәш ителә.



**Кысла**
**22.06-22.07**

Су Юлбарысы елы Кыслалар өчен бик кызыклы һәм вакыйгаларга бай булачак. Төп шарт – сәламәтлеккә сак караштa булу. Ә бу билге вәкилләренең физик сәламәтлеге турыдан-туры эмоциональ торышына да бәйле. Үз көчеңне дөрес бәяләргә, хезмәт һәм ял режимын сакларга киңәш ителә. Соңыннан үкенергә туры килмәс өчен, хис-тойгыларны өстен куярга ярамый. Ир-атларга да, хатын-кызларга да организмның төрле органнарына һәм системаларына игътибар итәргә кирәк. Ират Кыслаларга ашказаны-эчәк тракты һәм йөрәк-кан тамырлары системасына игътибар итәргә кирәк булачак.

2022 елга мәхәббәт йолдызнамәсен Кыслалар язмыш бүләге дип санарга мөмкин. Бу билгенең ялгыз вәкилләренә, ниһаять, үз яртысын очрату мөмкинлеге биреләчәк. Никахта булган Кыслаларга хисләрне «җылытырга», мөнәсәбәтләрне көйләргә, аларга «икенче сулыш» бирергә менә дигән мөмкинлек туачак.

Хезмәт эшләренә бөтен җентеклек белән карарга кирәк. Бу ел бик җаваплы булачак, шуңа күрә эштә вак-төякләргә дә җентекле булыгыз. Кысла билгесе астында туган иратларны Юлбарыс елында бик кызыклы һәм файдалы танышулар көтә, алар киләчәктә карьера үсеше өчен бик файдалы булачак. Ә хатын-кызлар Кыслаларга карьера һәм эш планындагы җитди үзгәрешләргә әзерләнергә кирәк. Аларны я инде эшләгән эшендә югарырак вазыйфага күтәрелү, я читтән яхшы тәкъдимнәр көтәчәк.

2022 елга Кысла өчен финанс йолдызнамәсе бик каршылыклы. Елның беренче яртысында эшләр бик алга бармаячак, өстәвенә, бурычларга "батарга" да туры киләчәк. Елның икенче яртысына эшләр җайланачак, ә кайберләрнеке алга ук китәчәк. Проблемаларны катлауландырмас һәм уңышны куркытмас өчен, берничә гади киңәш: елның беренче яртысында зур әйберләр (бигрәк тә автомобиль яки күчемсез милек) сатып алудан тыелыгыз. Сакчыл булыгыз, экономияләргә өйрәнегез.



**Арыслан**
**23.07-23.08**

2022 елда Арысланнар иҗади илһам дулкынын сизәчәк. Иҗатка һәм сәнгатькә тартылмаган Арысланнар да үзләрендә яңа талантлар ачачак. Нәкъ менә бу иҗади энергия күп кенә Арысланнарга карьера үсешенә һәм башка шәхси казанышларны башкарырга мөмкинлек бирәчәк.

Сәламәтлек ягыннан Арысланнарга Яңа ел бары тик уңышлар гына алып киләчәк. Спорт белән бергә атлаган бу билге вәкилләре алга таба үсеш мөмкинлекләрен кулдан ычкындырмаска кирәк. Йолдызлар Арысланнарга үзләре сайлаган спорт өлкәсендә үсәргә һәм яңа рекордларга омтылырга киңәш итә. Тормышларында спорт бөтенләй булмаган Арысланнарга бу юнәлештә эшләргә кирәк, чөнки хәрәкәттә – бәрәкәт.

Яздан уку һәм эшләү өчен иң яхшы вакыт башлана, сез үзегез өчен яңа өлкәләр һәм юнәлеш ача аласыз. Бер эш урынында күптән эшләгән Арысланнарга 2022 ел үз эшен ачарга яки эшчәнлек өлкәсен алыштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Акча Арысланнарны соңгы чиратта борчыячак. Беренче урында үз-үзен үстерү, җәмгыятьтә урыны, казанышлары белән бәйле башка мәсьәләләр булачак. Акча нинди дә булса максатларга ирешү өчен ярдәмче инструмент буларак кына каралачак. 2022 елга финанс йолдызнамәсе күрсәтүенчә, Арыслан финанс проблемалары кичермәячәк, тик аеруча зур хезмәт хакы, кисәк кенә бай туганнан мирас та көтәргә кирәкми.

Ялгыз Арысланнар, ниһаять, үзләренең икенче яртысын табачак. Озак вакыт очрашып йөрегән Арысланнар мөнәсәбәтләрен яңа дәрәҗәгә күчерү турында уйланачак. Бу мөнәсәбәтләрне законлаштыру яки бала табу да булырга мөмкин. Һәрхәлдә, үзгәрешләр уңай якка, ике як өчен дә көтеп алынган булачак.

# Юлбарыс елы ниләр вәгъдә итә

**Кызлар**
**24.08-23.09**



Кыз – тәртипне ярата, яхшылыкка һәм үзендә дә, тирә-юньдәгеләрдә дә кимчелекләрне бетерергә омтыла. Кызлар тормышының барлык өлкәләрендә диярлек булачак үзгәрешләр алдында тора. Шартлы рәвештә 2022 елны ике өлешкә бүләргә була: елның беренче яртысы – ял итү һәм көч туплау, икенчесе – уңышлы башлангычлар һәм актив эшчәнлек чоры. 2022 ел башы тыныч узачак. Сез үзегездә гражданлык һәм социаль активлык, көч кимүен, нәрсә дә булса эшләргә теләмәүне сизәргә мөмкин. Борчылмагыз һәм төшенкелеккә бирелмәгез. Барлык зур планнар һәм башлангычларны июль – август башына кадәр кичектерү яхшырак.

2022 елда сәламәтлеккә сак карашта булырга киңәш ителә. Көн тәртибен сакларга, эшләрне тәртипкә салырга һәм юк-бар өчен борчылмаска кирәк.

2022 елда Кызларны карьера баскычы буенча күтәрелү көтелә. Тик күктән төшкән бәхеткә өмет багларга кирәкми, барысы да үзегезгә, тырышлыгыгыз һәм максатчанлыгыгыз белән бәйле. Тулаем алганда, 2022 ел карьера буенча бик уңышлы булачак.

2022 елга финанслар йолдызнамәсе вәгъдә иткәнчә, Кызларга бу өлкәдә дә уңышлы булачак. Сездән зур финанс кертемнәрен таләп итә торган хәлләр сирәк булачак. Күчемсез милек һәм бизнеска кертемнәр яхшы нәтиҗә китерәчәк, әмма ышанычлы һәм тикшерелгән проектларга гына инвестицияләргә кирәк.

Мәхәббәт ягыннан Кызлар өчен Су Юлбарысы елы бик уңышлы булмый. 2022 елда яңа мөнәсәбәтләренең күбесе кыска вакытлы гына булачак. Гаиләле Кызларга хаталарын анализларга, икенче ярларының ихтыяҗлары турында да уйларга кирәк булачак.

**Үлчәү**
**24.09-23.10**



Су Юлбарысы елы Үлчәү билгесе астында туган кешеләрне дәртләндерергә мәҗбүр итәчәк. Тиз каралар кабул итәргә өйрәнгән Үлчәүләрне уңыш көтә.

2022 елга йолдызнамә Үлчәүләргә психоэмоциональ торышларына аерым игътибар бирергә киңәш итә. Стресслы хәлләр күп көтелә, сезнең бурыч – аларны дөрес бәяләргә. Рухи килешсезлек вакытында иммунитет сизелерлек кимергә мөмкин. Ә мондый чорда респиратор вируслы инфекцияләр организмга тиз генә һөҗүм итә. Бу билге вәкилләренә киңәш – чирне кисәтүгә зур игътибар бирегез. Ялны җәй көне яки көз башына планлаштырырга кирәк. Организм җибәргән сигналларга колак салыгыз. Бил һәм бөерләр – иң сизгер урыннар. Өшемәгез, арканың аскы өлешендә авырту сизсәгез, шунда ук табибка мөрәҗәгать итегез.

2022 елга карьера йолдызнамәсен Үлчәүләргә җентекләп өйрәнергә киңәш ителә, чөнки стандарт булмаган карарлар кабул итәргә өйрәнгән билге вәкилләрен генә алга китеш көтә. Үлчәүләр барысы да җентекләп анализларга өйрәнгән, нәтиҗәдә, алар иң яхшы хезмәткәрләр исәбендә түгел. Катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә тырышыгыз.

2022 ел финансларын җыя башларга кирәк. Табыш үсәчәк, шуның аркасында бу өлкәдә барысы да яхшы дип уйларга мөмкинсез. Әмма керемнәр белән беррәттән чыгымнар да арта башлаячак.

Су Юлбарысы елының мәхәббәт йолдызнамәсе мөнәсәбәтләрдә булган барлык Үлчәүләр өчен дә иминлек вәгъдә итә. Туй датасын планлаштырырга була – йолдызлар сезнең якта. Йөрәкләре яуланмаган Үлчәүләрне күп кенә романтик очрашулар көтә. Әгәр дә ялгыз Үлчәүләр гаилә корырга уйлый икән, моның өчен бар уңайлыклар да туры киләчәк.

**Чаян**
**24.10-22.11**



Чаяннар өчен 2022 елның гыйнвар ае иң уңышлы чор булмаячак. Бу вакытта сезне төрле күңелсезлекләр көтә. Монда гаепләрне эзләргә кирәкми, бары тик килеп туган проблемаларны хәл итү юлларын табарга кирәк булачак. 2022 елга йолдызнамә киңәш иткәнчә, Чаян үз эшләренең планын төгәл уйларга һәм аның буенча эш итәргә тиеш. Киләсе өч ай уңышлырак булачак, Чаяннарга бәхет елмаячак. Бу чорда яңа эш башларга яки тормышыңны тамырдан үзгәртергә кирәк. Чаян – ул көчле билге. Тормышта төрле хәлләр килеп чыга, шуны да онытмаска кирәк: бер яманның бер яхшысы була. Октябрь аенда көч һәм энергия сарыф итүне таләп итә торган чор башланачак.

2022 ел үз сәламәтлеген кайгыртмаучыларга бик уңышлы булмаячак. Әлеге билгенең күпчелек вәкилләре ел башында үзләрен начар хис итәчәк. Сәламәт яшәү рәвеше организмга уңай тәэсир ясаганын онытмагыз. Үзегезне стресслар һәм башка тормыш йөкләреннән саклагыз. Бу чорда эшчәнлекләре югары физик йөкләнешләр белән бәйле булган вәкилләрдә җитди авырулар булуы ихтималы аеруча зур. Әлеге категориягә спортчылар һәм машиналарның детальләре белән эшләүче кешеләр керә. 2022 елның төп кагыйдәсе – яман гадәтләр булмавы.

Мәхәббәт йолдызнамәсе әйтүенчә, мөнәсәбәтләрдә торучы Чаян өчен 2022 ел тотрыклы үтәчәк. Икенче яртысын тапмаганнар өчен Су Юлбарысы елы уңышлы булмаячак. 2022 ел аларга гаилә кору өчен иң уңайлы вакыт түгел. Шулай да бу чорда гаилә кора алсалар, ул ныклы булачак.

2022 елга финанс йолдызнамәсе фаразлаганча, Чаянны хезмәт эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә дә уңыш көтә. Барлык кертелгән тәкъдимнәр дә кабул ителәчәк һәм кулланылачак, барлык башлангычлар да яхшы нәтиҗәләргә китерәчәк. Бу коллективта эшләгән билге вәкилләренә генә түгел, ә үзмәшгульләргә дә кагыла.

**Укчы**
**23.11-21.12**



2022 елга йолдызнамә киңәш иткәнчә, Укчы барлык эшне дә акыл белән алып барырга һәм тормышны яхшы якка үзгәртүнең мөмкинлекләрен кулдан ычкындырмаска тиеш. Ел башы бу билге вәкилләрен чыдамлыкка сынаячак, әмма җәй көне аларга яхшы ял итү мөмкинлеге туачак. Көз һәм кыш башы чагыштырмача тыныч, үз-үзеңне камилләштерү һәм кадерле кешеләр турында кайгырту өчен уңайлы вакыт булачак.

Ел башы актив булачак. Эшләр озакка сузылмаячак, хроник авыруларның да кискенләшүе көтелми. Кыш һәм яз – тәнне һәм рухны тонуста тоту өчен менә дигән вакыт. Укчылар стрессларга бик бирешеп бармый, тик барыбер дөрес туклануны, вакытында ял итүне дә онытырга ярамый. 2022 елга Укчылар өчен йолдызнамә җәйге чорда экстремаль спорт төрләре белән шөгыльләнмәскә кисәтә. Бу имгәнүләргә һәм булган чирләрнең кискенләшүенә китерергә мөмкин. Ел азагы үз-үзеңне кайгырту чоры. Бу чорда Укчыларның нерв системасы һәм йөрәк игътибар таләп итәчәк. Ныклап тикшеренергә, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, стресска бирешмәскә һәм борчылмаска кирәк булачак.

Җитәкчелек һәр адымыгызны контрольдә тотмаячак. Хезмәт сөючән бу билге вәкилләре яңа вазыйфа, акча, яңа мөмкинлекләр белән бүләкләнәчәк.

Дөрес һәм үлчәп эш иткәндә, Укчылар акча белән кыенлык кичермәячәкләр. Кыш һәм яз айларында билге вәкилләре акрынлап үз керемнәрен арттырачак. Бу вакытта мөһим түгел әйберләргә акча әрәм итмәскә, иң кирәклеләре белән генә чикләнергә киңәш ителә. Барлык акчага бәйле сорауларны көзгә кичектерсәгез яхшырак булыр. 2022 елга финанс йолдызнамәсе фаразлаганча көзен Укчы яхшы табыш алачак.

Йолдызлар хәбәр иткәнчә, Укчыга 2022 ел мәхәббәт өлкәсендә уңышлы булачак. Ялгыз Укчыларны кызыклы шәхесләр белән танышу февраль-март айларында ук көтәчәк. Икенче ярларын тапканнар мөнәсәбәтләрен яңарту теләге барлыкка киләчәк. Җәй көне Укчылар гаиләсе һәм якыннары белән акча өчен бәхәскә керергә мөмкин. Тик хәлне катлауландырмаска кирәк. Кыенлыклар вакытлыча булачак, ә яраткан, якын кешеләр белән килешү инде җиңел булмаячак.

**Кәҗәмөгез**
**22.12-20.01**



Кәҗәмөгез өчен 2022 ел бик уңышлы башланачак. Юлбарыс бу билге вәкилләрен тыңларга һәм ишетергә өйрәтәчәк, димәк, шәхси тормышта да, карьерада да яхшы үзгәрешләр булачак.

Кәҗәмөгезләргә эчәклек торышына игътибар бирергә кирәк булачак. Организмда матдәләр алмашуга һәм ашкайнату процессларының бозылуына бәйле проблемалар булырга мөмкин. Кышкы айларда суык тию куркынычы бар, чирне кисәтүгә игътибар бирегез. 2022 елга йолдызнамә Кәҗәмөгезләргә спорт белән активрак шөгыльләнергә киңәш итә.

Эшкә сәләтлелек югары дәрәҗәдә булачак, бу, әлбәттә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк. 2022 елда карьера, бигрәк тә ел башында, тиз алга барачак. Бу вакытта уңышны кулдан ычкындырмаска кирәк. Җәй – квалификациягезне күтәрү вакыты. Көз тынычрак булырга охшаган. Карьера баскычы буенча хәрәкәтне дәвам итү мөмкинлеге барлыкка киләчәк.

2022 елга финанс йолдызнамәсе сөйләвенчә, Кәҗәмөгезләр үзләрен чагыштырмача тыныч хис итә ала. Алар алдында яңа мөмкинлекләр ачылачак, шуңа күрә Кәҗәмөгезләр тагын да зуррак уңышка ирешергә һәм зур әйбер сатып алуга яхшы капитал тупларга мөмкин. Юлбарыс елы финанс яктан шулай ук уңышлы тәмамланачак.

Ачык булыгыз, һәм Ел символы сезгә икенче ярыгызны табарга, тотрыклы мөнәсәбәтләр корырга ярдәм итәр. 2022 ел Кәҗәмөгезләргә, хәтта билге вәкилләренең иң оялчаннарына, кыюсызларына яхшы перспективалар ача. Ялгыз Кәҗәмөгезләргә 2022 елда танышу җиңелрәк булачак. Ә гаиләлеләргә йолдызлар уйланылмаган гамәлләр кылмаска киңәш итә. Төзәтә алмаслык хата ясау ихтималы зур.

**Сукояр**
**21.01-20.02**



2022 елга йодызнамә сөйләвенчә, Сукояр төрле планнар корып, максатлар билгеләп, аларны тормышка ашыру буенча кыю рәвештә хәрәкәт итә ала. Гомумән алганда, бу билге вәкилләре өчен 2022 елга йолдызнамә нинди дә булса кыенлыклар, шул исәптән сәламәтлек белән бәйлесен дә, вәгъдә итми. Актив яшәү рәвеше, начар гадәтләрдән баш тарту һәм яхшы кәеф – Сукоярлар өчен ел дәвамында үз-үзен яхшы хис итәргә ярдәм итүче факторлар. Психологик йөкләнешләр, борчулар кайбер авырулар китереп чыгарырга һәм иммунитетны өзәргә сәләтле. Йолдызлар Сукоярларга төрле яман уйлардан баш тартырга, үз-үзләрен кулда тотарга киңәш итә. Йөзү, иртәле-кичле саф һавада йөрү шулай ук стресска каршы көрәштә ярдәм итәчәк.

Бу билге вәкилләре, гадәттә, хезмәт мәсьәләләрендә уңышка ирешергә күнеккән, 2022 ел алар өчен искәрмә булмаячак. Юлбарыс та аларга үз мөмкинлекләренә ышанычларын ныгытырга ярдәм итәчәк. Сукоярларга бәхет һәм уңыш 2022 елның октябренә кадәр барлык эшләрдә дә юлдаш булачак. Алга таба аларның активлыклары кимиячәк һәм хәлләр бераз үзгәрәчәк. 9 октябрьдән соң җитди эшләр башларга кирәкми. Шуңа күрә карьераны алга җибәрү белән бәйле барлык мөһим мәсьәләләрне сентябрь ахырына кадәр хәл итү яхшырак булыр.

2022 елның беренче өч аенда Сукоярлар тормышының финанс ягы бер алга, бер артка барачак. Ә елның икенче яртысында билге вәкилләренең финанс хәле шактый яхшырачак. Бу вакытта яңа уңышлы проектлар һәм файдалы тәкъдимнәр булуы ихтимал.

2022 елга мәхәббәт йолдызнамәсе фаразлаганча, Сукоярларга каршы җенес ягыннан зур игътибар булачак. Ялгыз Сукоярларга якын-тирәдәгеләргә күз салырга киңәш ителә. Яңа мөнәсәбәтләр өчен уңышлы чор 15 апрельдән соң башланып, сентябрь ахырына кадәр дәвам итәчәк.

**Балык**
**21.02-20.03**



Көнчыгыш календаре буенча Су Юлбарысы елы 2022 елның 1 февралендә башлана һәм су билгесе астында узачак. Бу, әлбәттә, Балыклар өчен уңай шартлар тудырачак. 2022 елда иҗади кешеләр үз стихиясендә булачак. Музыка коралларында уйнарга өйрәнегез, рәсем ясагыз, дизайн белән шөгыльләнегез.

Балыкларга Юлбарыс елында сәламәтлекләрен табигатькә чыгып, яраткан музыкасын тыңлап, театрга барып ныгытырга кирәк. Шифаханәгә баруны көз азагы-кыш башына планлаштыру яхшырак.

Финанс йолдызнамәсе искәртүенчә, бу билге вәкилләренә керем алуга яисә лотереяда җиңүгә ышанып, зур суммага бурычка алмаска. Акчалата иминлек февраль, март һәм апрель айларында гына оптималь булачак. Май аенда көтелмәгән югалтулар булу куркынычы бар. Бу вакытта кредит яки бурычка алу хата булачак. Җәйге айлар керем ягыннан тотрыклы үтәчәк.

2022 елда Балык өчен карьера вазыйфалы кеше белән танышканнан соң үсеп китәргә мөмкин. Ел азагында эш урынын алыштырырга уйламагыз. Отпуск өчен иң яхшы вакыт – март, җәйнең икенче яртысы яки ел азагы.

Юлбарыска дәртлелек хас. Шуңа күрә озак вакытка сузылмаячак мөнәсәбәтләр барлыкка килү куркынычы бар. 2022 елга мәхәббәт йолдызнамәсе Балыклар өчен ныклы мөнәсәбәтләр вәгъдә итми. Декабрь аеннан никахлашу турында уйланыгыз.

**Зәһинә ИБӘТУЛЛИНА әзерләде.**

# *Ихлас теләкләр!*

Яңа Бикмәт авылында гомер итүче, сабыр, изге күңелле, безнең өчен бик кадерле әтиебез – **Корбангалиев Зәвирҗан Фәрит улы**! Сине гомер үрләрен яулыйяулый шушы баскычка килеп җиткән матур юбилееӊ белән котлыйбыз. Гаиләҗанлы, әниебезнең, балаларыңның, оныкларыңның ныклы терәге, таяны-чы, кешелекле, ярдәмчел, игътибарлы булганың өчен мең-мең рәхмәт сиңа.

*Рәхмәт, әти, барысы өчен рәхмәт,*
*Булдың безгә һәрчак зур терәк.*
*Синең насыйхәт безгә гел кирәк,*
*Синдәй әтиләр җирдә бик сирәк.*
*Гомерләрең озын булсын, әти,*
*Бәхетләрең булсын гомерле.*
*Белеп яшә: безнең өчен җирдә*
*Син – иң изге һәм иң кадерле.*

Син безнең ышаныч та, саклаучыбыз да, яклаучыбыз да. Алдагы көннәрдә дә әниебез белән иңне-иңгә куеп, парлашып, бер-берегезнең күңел яктылыгын, җан җылысын тоеп, тынычлыкта, муллыкта, сау-сәламәт, бәхетле булып яшәргә насыйп булсын. Туачак таңнарың һәрвакыт нурлы, күк йөзең аяз булсын.

**Сине яратып, хөрмәт итеп, кызларың Әлфидә, Флисә, кияүләрең Динар, Петр, оныкларың Давид, Ульяна.**

Кадерле тормыш иптәшем Зәвирҗан! Сәламәтлегең ныклы, көннәрең кояшлы, гомерең озын, бәхетләрең мул булсын. Тигез тормышта, бер-беребезгә терәк булып, гаиләбезнең учагын сүндермичә, гомер көзләрен дә, кышларын да бергә каршылыйк.

*Яхшы әти дә син, яхшы ир дә,*
*Игелекле дуска, туганга.*
*Акыллы ул булдың әнкәйгә,*
*Без бәхетле җирдә син барга.*
*Кайгы-хәсрәт мәңге юл тапмасын*
*Безнең тату, бердәм ояга.*
*Пар канатлы булып тигез яшик*
*Бәхет-шатлык татып дөньяда.*
*Ак бәхетләр сиңа юлдаш булсын,*
*Үткән чакта гомер юлларын.*
*Онытма син авыр минутларда*
*Сине аңлар кеше – мин барын.*

**Иң изге теләкләр белән, тормыш иптәшең Флинә.**

Бүген безнең иң кадерле кешебез,тормыш иптәшем, газиз әниебез, әбиебез, нәнәебез, кодагыебыз – **Раушания Кадим кызы Ногманова** туган көнен бәйрәм итә.

Яратканыбыз, сине 55 яшьлек юбилееӊ белән чын күңелдән котлыйбыз һәм иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Әтиебез белән безне кадерләп үстереп, үз юлыбызны табарга булышканыгыз, яратып кайгыртканыгыз өчен зур рәхмәт. Сиңа зур уңышлар, шатлыклы очрашулар, көтелмәгән куанычлар һәм бәрәкәтле озын гомер телибез. Ходай биргән гомереңне сәламәт булып, күңел тынычлыгында, кайгы-хәсрәтсез, борчу-мәшәкатьсез, шатлык-сөенечләр белән, туганнарыңның таянычын күреп, кадер-хөрмәттә яшәргә язсын. Киләчәктә дә әтиебез белән пар канатлар булып, тынычлыкта, муллыкта, без – балаларыгызның, оныкларыгызның игелеген, рәхәтен күреп, озын-озак, тигез гомер итәргә булсын сезгә!

*Яшәү терәге син безнең өчен,*
*Кешелегең белән үрнәк син.*
*Мең-мең рәхмәт, дибез, әни,*
*Безнең өчен һәрчак кирәк син!*

**Сине яратып, хөрмәт итеп,тормыш иптәшең Фәнзир, кызларың Гүзәл һәм Гөлнара, киявең Рөстәм, оныгың Софья, кода-кодагыең Динар – Ләйсән.**



Иске Тукран авылында яшәүче кадерле әниебез **Гыйләҗева Фәйрүзә Хәмит кызының** һәм **әтиебез Гыйләҗев Фидәрис Кәшфи улының** күркәм юбилейлары! Без аларны чын күңелдән котлыйбыз. Көннәрегез шатлык белән үтсен, гомер юлларыгыз озын булсын, кайгы-хәсрәт күрми, һаман шулай безгә терәк булып яшәгез. Төпле киңәшегез, җылы сүзегез, нурлы йөзегез өчен рәхмәт сезгә.

*Сез бит әти-әни яшәешнең яме,*
*Безнең өчен олы терәк.*
*Тыныч яшәң, берүк,*
*исән-сау булың,*
*Сез бит әле безгә бик кирәк.*
*Салкын карлы кышта*
*тусагыз да,*
*Яз кояшы һәрчак күңелегездә.*
*Һәрвакытта йөзегез көләч булсын,*
*Балкып яшәң гомер-гомергә.*

**Иң изге теләкләр белән, улыгыз Фидәрит, киленегез Гөлнара, оныкларыгыз Альмир, Дамир, кызыгыз Илмира, киявегез Альмир.**

Иске Тукран авылында яшәүче **Гыйләҗев Фидәрис Кәшфи улын** һәм **Гыйләҗева Фәйрүзә Хәмит кызын** юбилейлары белән чын күңелдән котлыйбыз! Сезгә хәерле-бәрәкәтле озын гомер, ныклы сәламәтлек, куанычлы шатлыклы көннәр телибез. Фәйрүзә туганыбыз уңган, кунакчыл, һәрвакыт тәмле ризыклар әзерли, бәйләмгә оста, ишегалды тулы шау чәчәкләр үстерә.

Гомер буе савымчы булып эшләде, депутат булып сайланды, бик күп Мактау грамоталары бар. Алар әлегә кадәр мал карап, кош-корт асрап гомер итәләр. Аларга киләчәктә дә бәхеткә төренеп, туар таңнарын гел шатлыклар белән каршыларга язсын. Фидәрис җизнәй белән парлы, тигез гомер итеп, балалар кадер-хөрмәтендә яшәргә насыйп итсен Ходай.

*Җирдә чишмә, күктә кошлар*
*Сезгә атап җыр җырласын.*
*Дусларыгыз, туганнарыгыз*
*Сезне шулай гел зурласын.*

**Иң изге теләкләр белән, апагыз Фәридә, сеңелегез Гүзәлия, кияүләрегез Валерий, Ришад.**


**Сатыла-продается**

*КРС на мясо. Тел.: 89177615871. КФХ Асфандияров И.И. Св. 316028000075364. Реклама

***

*Бычки. Возможна доставка. Тел.: 8-927-818-63-13. Реклама

***

Срубы для бани и дома с пиломатериалами. Доставка. Тел.: 8-952-646-51-28. ИП Гафуев Р.С. Св. 319595800092455. Реклама

***

*Кролики породы серые великаны, французские бараны. Крупные шестимесячные самцы и самки. Тел.: 89875801931. Реклама

***Реализуем жеребцов (молодняк), живым весом с откорма. Звонить по телефонам: 89033113295, 83475326619, 89177520099 (с 9-00 до 18-00 часов).**

ООО СХП «Мотор». ОГРН 1070217000040. Реклама

**Госаптека № 44** РЕКЛАМА
(с. Бураево, ул. Советская, д. 20/1)
***10 января с 13.30 до 14.30 ч.***
**"РАДУГА ЗВУКОВ"**
**СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ**
аналоговые, цифровые
Цена: от **7 700** до **18 000** руб. (Россия, Дания, Германия)
**Справки и заявки на дом по тел: 8-901-866-81-57**
*Сдайте один старый аппарат и получите скидку при покупке нового аппарата 7 %*
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА
ОГРН 304183133700096 ИП Вилков В.А.

**Төрлесеннән-разное**

Закупаю гусиный пух по 500 рублей (мокрые тоже). Подушки и перины. Можно обмен на одеяло, подушки. Тел.: 8-937-311-80-72. ООО "Экопух". Св. 1070278012716. Реклама

***

Ремонт холодильников, морозильников, стиральных машин-автоматов. Гарантия. Качество. Тел.: 8-927-334-18-25 (Марат). ИП Мустафин М.М. Св. 311027115700016. Реклама

***

Куплю земельный участок от 15 соток. Тел. 89871040204. Реклама

***

*Итләтә һәм тереләй мал сатып алам. Тел. 89174354104. КФХ Асфандияров И.И. Св. 316028000075364. Реклама

***

Откачка канализаций, туалетов. Выезд по деревням. Тел.: 8-917-779-71-75 (Тагиров Ф.Ф.). Реклама

***

Ремонт холодильников на дому. Продажа б/у холодильников. Тел.: 8-927-338-27-30, 8-987-616-96-48. Реклама

***

Выкуп автомобилей в любом состоянии. Тел.: 8-987-587-98-75. Реклама

***

Мойка ковров. Приедем – заберем, помоем, высушим, привезем. Тел.: 8-987-614-01-24. Реклама


***

***Реализуем гусей с откорма в деревне Курачево. Количество ограничено.**
**Телефоны: 89603845320, 83475326619, 89177520099.**

ООО СХП «Мотор». ОГРН 1070217000040. Реклама

**Пеноблоки. Керамзитоблоки. Пеностирольные блоки.**
Тел.: **8-917-410-32-48.**
ИП Тимашев В.Р. Св. 304026406300232. Реклама

**Закупаем:**
***коров, быков, лошадей. Дорого.**
Тел: **8-906-101-11-33**
ИП Зарипов Р.А. Св. 316028000076014.
Реклама




**Извещение о месте и порядке ознакомления с проектом межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей**

Заказчиком работ по подготовке проекта межевания является Тухватова Фанида Ханифовна, почтовый адрес: 452684, РБ, г. Нефтекамск, ул. Социалистическая, д. 2, кв. 40, тел.: 89053091727.

Проект межевания подготовил кадастровый инженер Гарифулин Марат Ринатович, номер квалификационного аттестата 02-16-1401. Почтовый адрес: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, эл. почта: garifulin1986@yandex.ru, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Земельный участок выделяется в счет земельных долей в праве общей долевой собственности из исходного земельного участка с кадастровым номером 02:17:000000:956, адрес (местоположение): РБ, Бураевский район, Бадраковский с/с.

С проектом межевания можно ознакомиться у заказчика работ по адресу: РБ, г. Нефтекамск, ул. Социалистическая, д. 2, кв. 40, тел.: 89053091727 или у кадастрового инженера по адресу: РБ, Бураевский район, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Предметом согласования являются размер и местоположение границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка.

Предложения о доработке проекта межевания земельного участка, обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ в счет земельных долей земельного участка по проекту межевания следует вручить или направить в течение 30 дней со дня опубликования настоящего извещения по адресу: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106 и в Филиал ФГБУ (ФКП Росреестра) по Республике Башкортостан по адресу: 450059, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50 лет СССР, д. 30/5. Реклама

Каенлык урта мәктәбе коллективы, профсоюз оешмасы, ашханә хезмәткәре Галиева Энҗе Әсләм кызының сөекле

**ӘТИСЕ**

вафат булуын тирән кичереп, аның, әнисенең, якыннарының, туганнарының авыр югалту кайгыларын уртаклаша һәм сабырлык тели.

Ленин исемендәге хуҗалык идарәсе, ветераннар советы, хуҗалыкта эшләп лаеклы ялга чыккан хезмәт ветераны

**КАРАМОВА Фәгыймә Салих кызы**

вафат булу сәбәпле, мәрхүмәнең балаларының, туганнарының авыр кайгыларын уртаклаша.

Район мәгариф бүлеге, профсоюз оешмасы, лаеклы ялдагы Фазлутдинова Әлфия Хәмит кызының сөекле тормыш иптәше

**ФАЗЛУТДИНОВ Роберт Даһи улы**

вафат булуын тирән кичереп, аның, балаларының, якыннарының авыр югалту кайгысын уртаклаша һәм сабырлык тели.

Ваныш-Алпавыт авылы мәктәбе коллективы, профсоюз оешмасы, ветеран-укытучы

**ЯМИНЕВА Халисә Хәбибрахман кызының**

вафат булуын тирән кичереп, мәрхүмәнең балаларының, якыннарының авыр югалту кайгысын уртаклаша һәм сабырлык тели.

Шабай "Үсеш" гаилә тәрбиясе бирүгә булышлык итү үзәге администрациясе, профсоюз оешмасы, "Үсеш" үзәгенең водителе Вәлиев Радис Сәхиб улының бертуган энесе

**ВӘЛИЕВ Ильберт Сәхиб улының**

вафат булуын тирән кичереп, аның, якыннарның, туганнарының авыр кайгыларын уртаклаша һәм сабырлык тели.

# Ихлас теләкләр!

Борай авылында гомер итүче әтиебез **Хәертдинов Лотфирахман Хәйбрахман улының** 11 гыйнварда 90 яшьлек юбилее. Кадерлебез, сине гомер бәйрәмең белән котлыйбыз. Сиңа кояш нурыдай аяз көннәр, исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, озын гомер, ак бәхетләр телибез. Алдагы гомер юлларың бары тик шатлыкта гына үтсен, гел безне сөендереп, бергә-бергә озын-озак яшә син.

*Котлы булсын, әткәй,*
*туган көнең,*
*Матур булып атсын таңнарың.*
*Рәхәт яшә, игелеге кайтсын*
*Син үстергән һәрбер балаңның.*
*Әтиебез – безнең кадерлебез,*
*Без бәхетле җирдә, син барга.*
*Фәрештәләр кунсын иңнәреңә*
*Туган көнең белән котларга.*

**Изге теләкләр белән, сине яратып, балаларың, оныкларың.**



Иске Бикмәт авылында гомер итүче кадерле тормыш иптәшем, яраткан әтиебез, дәү әтиебез **Зиннуров Әнвәр Зекри улы** 2 гыйнварда 85 яшьлек күркәм юбилеен каршылады. Әти, чын күңелдән, ихлас йөрәктән шундый якты бәйрәмең белән котлыйбыз. Кояштай озын гомер, гомерең буена җитәрлек ныклы сәламәтлек, шатлык-сөенечләр, олы бәхетләр телибез. Балаларыңның, оныкларыңның, кардәш-туганнарыңның шәфкатьлелеген, мәрхәмәтлелеген, игътибарын, ихтирамын тоеп, әниебез белән хәерле, тыныч тормышта гомер итүеңне телибез. Өстәлләрегез түгәрәк, мул булсын. Аллаһы Тәгалә акыл сафлыгы, иман байлыгы бирсен. Картлык көннәрең бары тик шатлыкта гына үтсен. Гел шулай көләч, ягымлы бул, безне сөендереп, озак яшә.

*Туган көнең котлы булсын,*
*Җылы булсын карашың.*
*Йөрәк бәхет белән тулсын,*
*Бәйрәм булсын тормышың.*

**Изге теләкләр белән, тормыш иптәшең, балаларың, оныкларың.**



Яңа туган 2022 ел Мәкъсүтовлар гаиләсенә аеруча шатлыклы олы бәйрәм алып килә. **Рәвис Мөбарәк улы Мәкъсүтовка** 10 гыйнвар көнендә 70 яшь тула. Шушы уңайдан без, юбилярның балалары аны күркәм бәйрәме белән котлап, күңелдәге изге теләкләрне юллыйбыз. Кадерле әтиебез! Синең кебек саф күңелле әтиләр бу дөньяда бик сирәк. Балаларым бәхетле булсыннар дип күпме эшләр башкардың, тырыштың, булдырдың. Һәрбер изгелекләрең өчен юбилей көнендә чиксез рәхмәтләр белдерәбез, синең алдыңда баш иябез. Әниебез, Фәнзия Сәгыйть кызы белән мәхәббәттә, сау-сәламәт булып, озын гомерләр кичерергә Ходай насыйп итсен үзеңә. Балалар-оныклар куанычын күреп, туганнар, дусларыңның хөрмәтен сизеп, алга таба да борчу-мәшәкатьләрсез мең яшә. Без сине бик тә яратабыз, хөрмәт итәбез. Юбилей бәйрәмең белән сине.

*Юбилейда һәркем хәтер белән*
*Сүтеп чорный уйлар йомгагын.*
*Тулы булсын сөенечләр белән*
*Киләчәккә илтер гомер еллары.*
*Әтиебез, йөзгә җиткәндә дә*
*Дәртле булсын йөрәк тибешең.*
*Матурлардан матуррак булсын*
*Гомереңнең калган өлеше.*
*Сабый чакта кулларыңа алып,*
*Зур үсегез диеп*
*безне күккә күтәрдең,*
*Балам диеп,*
*башларыбыздан сыйпап,*
*Сабырлыкка безне өйрәттең.*
*Чәчләреңә төшкән карларыңны*
*Алып ташлап булмый кул белән,*
*Һаман әле ныклы атлыйбыз без*
*Син күрсәткән, әти, юл белән.*

**Иң изге теләкләр белән, сине яратып, улларың Илнур, Марат, кызың Эльвина, киленнәрең Светлана, Анна, киявең Илшат, оныкларың Камил, Эмиль, Аскар, Мәдинә һәм Энҗе.**

Борай авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, әтиебез **Мәхмүтов Илдар Мулланур улы** олы юбилеен билгеләде.

40 елга якын Борай районы буенча дәүләт техник күзәтү инспекциясе җитәкчесе булып эшләп район халкы арасында зур абруй казанды. Эшенә бар белемен, көчен, намусын, тырышлыгын салып эшләде.

Кадерле әтиебез! Син тормыш баскычлары аша күтәрелеп, алга горур атлавыңны дәвам итәсең. Син далаларның мәгърур лачыны сыман күп нәрсәләрне алдан күрәсең, алдан сизенләп беренче ярдәмгә килергә һәрвакыт әзерсең. Юбилееең белән котлап, иң изге, матур теләкләребезне юллыйбыз: көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт бул. Уй-теләкләрең киң, туар таңнарың тыныч, саулыгың ныклы, гомерең бәхетле булсын. Тормышыбызга ямь өстәп, авырмый, кайгы-хәсрәт күрми әниебез белән тормыш юлыннан тигез атлагыз. Төпле киңәшең, җылы сүзең, нурлы йөзең өчен рәхмәт. Рәхмәт сиңа, әти, барысы өчен дә.

*Олы рәхмәт,*
*җылы сүздән башка*
*Табып булмый иң зур бүләкне.*
*Безнең өчен бигрәк кадерле син,*
*Бигрәк якын, бигрәк кирәкле.*

**Иң изге теләкләр белән, тормыш иптәшең Илира, улың Айдар, киленең Миләүшә.**



Яраткан тормыш иптәшем, әтиебез, дәү әтиебез **Галиәхмәтов Фәнзәви Кавый улы** 70 яшьлек олы юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Кадерлебез! Син безнең таянычыбыз, ышанычыбыз, киңәшчебез. Барысы өчен дә мең рәхмәт әйтеп, сиңа ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, шатлык-куанычлар белән тулы бәрәкәтле озын гомер телибез. Киләчәктә дә балаларыңның игелеген күреп, оныкларыңа сөенеп, әни белән тигезлектә, муллыкта, саулыкта яшәргә язсын.

*Син булганда*
*безнең тормыш матур,*
*Син бит безгә олы бер терәк.*
*Матур яшә, берүк исән-сау бул,*
*Син бит, әти, безгә бик кирәк.*

**Иң изге теләкләр белән, тормыш иптәшең Анфиса, балаларың Ирина – Илшат, Ирек – Алсу һәм оныкларың.**


**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ ОБЩЕГО СОБРАНИЯ УЧАСТНИКОВ ОБЩЕЙ ДОЛЕВОЙ СОБСТВЕННОСТИ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА С КАДАСТРОВЫМ НОМЕРОМ 02:17:000000:946**

Администрация сельского поселения Кашкалевский сельсовет МР Бураевский район РБ извещает участников общей долевой собственности земельного участка с кадастровым номером 02:17:000000:946 (местоположение: Республика Башкортостан, Бураевский район, Кашкалевский сельсовет) о проведении общего собрания участников долевой собственности.

Собрание состоится 16 февраля в 10:00 ч. по адресу: РБ, Бураевский район, д. Старокарагушево, ул. Мира, д. 10, в здании сельского клуба. При себе иметь следующие документы: паспорт и свидетельство о государственной регистрации права.

**ПОВЕСТКА ДНЯ:**

1. Выборы председателя собрания.
2. Выборы секретаря собрания.
3. Утверждение:

- проекта межевания земельного участка;
- перечня собственников земельного участка, образуемого в соответствии с проектом межевания земельного участка;
- размера долей в праве общей долевой собственности на земельный участок, образуемый в соответствии с проектом межевания земельного участка.

4. Назначение уполномоченного лица.

Кадастровые работы проводит кадастровый инженер Гарифулин Марат Ринатович. Номер квалификационного аттестата 02-16-1401. Почтовый адрес: РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, 106, (2 этаж, вход с торца), garifulin1986@yandex.ru т. 8(34756)2-01-74.

С документами по вопросам, вынесенным на обсуждение общего собрания, можно ознакомиться в течение 40 дней со дня опубликования данного извещения по адресу: ООО «Геостройинжиниринг», РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, 106 (2 этаж, вход с торца), т. 8(34756)2-01-74. Реклама

**Извещение о месте и порядке ознакомления с проектом межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей**

Заказчиком работ по подготовке проекта межевания является Хузина Гульниса Сафовна, почтовый адрес: 452975, РБ, Бураевский р-н, д. Силосово, ул. Озерная, д. 8, тел.: 89053551388.

Проект межевания подготовил кадастровый инженер Гарифулин Марат Ринатович, номер квалификационного аттестата 02-16-1401. Почтовый адрес: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, эл. почта: garifulin1986@yandex.ru, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Земельный участок выделяется в счет земельных долей в праве общей долевой собственности из исходного земельного участка с кадастровым номером 02:17:000000:956, адрес (местоположение): РБ, Бураевский район, Бадраковский с/с.

С проектом межевания можно ознакомиться у заказчика работ по адресу: РБ, Бураевский р-н, д. Силосово, ул. Озерная, д. 8, тел.: 89053551388 или у кадастрового инженера по адресу: РБ, Бураевский район, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106, тел.: 8 (34756)2-01-74.

Предметом согласования являются размер и местоположение границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка.

Предложения о доработке проекта межевания земельного участка, обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ в счет земельных долей земельного участка по проекту межевания следует вручить или направить в течение 30 дней со дня опубликования настоящего извещения по адресу: 452960, РБ, Бураевский р-н, с. Бураево, ул. Ленина, д. 106 и в Филиал ФГБУ (ФКП Росреестра) по Республике Башкортостан по адресу: 450059, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50 лет СССР, д. 30/5. Реклама


*В соответствии с требованиями действующего законодательства перемещение всех видов животных и продукции животного происхождения должны осуществляться под контролем госветслужбы по ветеринарным сопроводительным документам.


Учредители: Агентство по печати и средствам массовой информации Республики Башкортостан, Государственное унитарное предприятие Республики Башкортостан Издательский дом «Республика Башкортостан». Общественно-политическая газета "Алга" муниципального района Бураевский район Республики Башкортостан издается с 19 февраля 1930 года. Выходит во вторник и пятницу на татарском языке.

Алга

Баш редактор
В.М.АРСЛАНОВА

Гәзит элемтә һәм киңкүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтнең Башкортстан Республикасы буенча идарәлегендә 2015 елның 1 сентябрендә теркәлде. Теркәү саны ПИ № ТУ 02-01438. Тиражы 2756 данә. Күләме бер шартлы басма табак. Форматы 12хА3.

Редакциянең адресы: 452960, Башкортстан Республикасы, Борай районы, Борай авылы, Вострецов урамы, 37. Телефоннар: Редактор /факс/ 2-11-81, җаваплы секретарь, хатлар бүлеге 2-13-81, авыл хуҗалыгы бүлеге 2-17-30, бухгалтерия, реклама,котлаулар, белдерүләр /факс/ 2-17-36. E-mail: ALGA@ufamts.ru.
Нәшер итүче – «Республика Башкортостан» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесенең адресы: 450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13.
Гәзит редакция компьютерында җыелды һәм версткаланды, офсет ысулы белән басылды.

Автор фикере редакция фикере дигән сүз түгел. Редакция мәҗбүри хат алышу алып бармый. Кульязмаларга рецензия ясалмый һәм алар кире кайтарылмый. Имзасыз хатлар каралмый. «Юбиляр», «Хәтер», «Рәхмәтлебез» рубрикалары астындагы язмалар түләп бастырыла.
Гәзит басуның сыйфаты өчен типография җаваплы.

ИНДЕКСЫ ПО583. Заказ № 21. Гәзиткә кул кую вакыты – 30 декабрь, 15 сәгать. Кул куелды – 14.40 сәгатьтә. Гәзит Бөре мәгълүмат үзәге – «Республика Башкортостан» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалында басылды. Адресы: 452450, Башкортстан Республикасы, Бөре шәһәре, Ленин урамы, 56. Телефон: (8-34784 ) 2-25-60.

**Басма Русия Федерациясенең Цифралы үсеш, элемтә һәм киңкүләм коммуникацияләр министрлыгының финанс ярдәме белән дөнья күрә.**